www.assalam.ru
www.islamdag.ru
assalamweb@gmail.com

12+

# ӘС-СӘЛӘМ

ДИН-МӘГЪРИФӘТ ГАЗЕТАСЫ

Бәясе ирекле

АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘГӘ МАКТАУЛАР БУЛСЫН!

Рабигылахыр 1438 ел. 1994 нче елдан бирле бастырыла. № 1(02) / 15 гыйнвар 2017 ел.


# ИМАН ЮЛДАШ БУЛСЫН БЕЗГӘ!

**МӨРШИДӘ КЫЯМОВА**

**ЯҢА МӘЧЕТЛӘР АЧЫЛДЫ**

Узган елда Татарстан Аллаһ йортларына да шактый баеды.



2016 ел Татарстан Диния нәзарәте өчен шактый катлаулы, әмма нәтиҗәле ел буларак истә калыр, мөгаен. Татарстан мөселманнары лидеры мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин үзе дә шул фикердә.

– Диния нәзарәте яңа урында эшли башлады. Тукай урамына күчтек, мәчетле булдык. Аллага шөкер, бик матур тарихи гыйбадәтханәбез – Галиев мәчете төзекләндерелде. Яңа комплекска күчүнең мәшәкатьләре шактый булса да, бу – бик сөенечле хәл. Моның өчен без республика җитәкчеләренә рәхмәтле. Аларның ярдәме белән зур кунакларны каршы алыр һәм төрле ил вәкилләре белән сөйләшүләр оештырыр өчен матур бинабыз булды. Икенче тарихи мизгел ул – Коръәннең яңа басмасын әзерләп, 10 мең тираж белән нәшер иттек. Ике ел дәвамында бу зур эшне Коръәнне өйрәнү бүлеге, Коръән-хафизларыбыз башкарып чыкты. Хәзер исә Коръәннең яңа басмасын 5 мең данәдә кабат бастырабыз, – дип шатлыгы белән уртаклашты Татарстан мөфтие.

Яңа мәчетләр ЯрЧаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә, Яшел Үзән, Бөгелмә, Балтач, Кайбыч, Кукмара, Балык Бистәсе, Актаныш һ.б. районнарда үз ишекләрен ачты. Диния нәзарәтеннән алынган мәгълүматларга караганда, республикада 2016 елда 20дән артык яңа мәчет эшли башлаган. Моннан тыш, шактый гына иман йортлары төзекләндерелде. Мөхтәсибәтләргә, хәзрәтләргә грантлар бирү дәвам итәчәк. Әлеге грантлар авыл мәчетләренә ярдәм йөзеннән тәгаенләнгән. Яшь имамнарга 180 мең сумлык сертификатлар бирү дә күркәм гамәллләрдән санала. Быел 50дән артык кешегә грант тапшырылган.

2017 елның шактый җаваплы булачагын да яшерми дин әһелләребез. «Болгар ислам академиясе ачылачак. 1 сентябрьдә без академиядә яңа уку елын башлап җибәрергә тиеш. Бу эшләр республика, хәтта Россия күләмендә генә бармый. Чит илләр белән даими сөйләшүләр үткәрелә. Безнең барыбызга да, бигрәк тә Голәмәләр шурасына, мәгариф бүлегенә академиянең уку-укыту планнарын төзү өчен шактый эш башкарырга туры киләчәк. Вакыт күп түгел, санаулы айлар гына калып бара», – ди мөфти.

НӘСЫЙХӘТ

## Мәүлид ән-Нәби

“

Идел буе һәм Кавказ мөселманнары Аллаһның бар ике дөньяга да рәхмәте - Мөхәммәд Пәйгамбәрнең ﷺ туган көнен бәйрәм итүгә һәрвакыт аерым бер әһәмият биргәннәр, бу вакытта нәфел намазлар, Коръән укыганнар, салават әйткәннәр Мөхәммәд Пәйгамбәргә ﷺ сәламләүләр җиткергәннәр. Бу - Аның Рәсүлен ﷺ искә алу аша Аллаһка гыйбадәт кылуга өстәмә мөмкинлекләр бирә. Аллаһның Рәсүлен ﷺ сәламләүнең, искә алуның файдасы турында Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъват бүлеге белгече Тимергали хәзрәт Юлдашев сөйли.

БИТ 7

“

ГЫЙБАДӘТХАНӘ

## Рамазанга әзерләнер вакыт

Изге Рамазан ае якынлашкан саен мөселман кардәшләрдән: «Уразага ничек әзерләнергә?» соравы ешрак ишетелә башлый. Аеруча шәрәфле ай җәйге озын көннәргә туры килсә. Соңгы елларда, Раббыбызның рәхмәте илә, безнең җирлектә фарыз ураза сын җәен тотабыз. Шул сәбәпле, диннән әлегә ераграк булган таныш-белешләр: «Көннәр бигрәк озын, бик эссе бит – ничек кенә тотарсыз икән», – дип, «ярага тоз сала». Җирдәге кызуга ничек тә түзәрбез, Аллаһы Тәгалә җәһәннәм утыннан сакласын.

БИТ 3

## Пәйгамбәребез юлы – безгә маяклы юл

ИНСАН ТАВИЛЕВ

Мөселман дөньясы күтеп алган һәм бик яратып билгеләп үткән Мәүлид ән-Нәби ае да артта калды. Аллаһ рәхмәте, 2016 елны аны ике тапкыр олыладык: елны Рабигуль әүвәл белән башлаган идек, декабрь да һиҗри айлар исәбе белән безгә Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафане ﷺ биргән Рабигуль әүвәлгә туры килде. Аллага шөкер, авыл җирләрендә дә, калалардагы мәчет-мәхәлләләребез дә шушы уңайдан төрле-төрле чаралар оештырдылар.




Халкыбыз шул рәвешле татарлар күңеленә салынган, гасырлардан гасырларга дәвам иткән матур гадәтен - Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафагә ﷺ карата булган кадер-хөрмәтен, олылавын җиткерде. Нияте бер булса да, мондый мәҗлесләр һәр җирдә бер-се-берсен кабатламыйча, үзенә бер җылылыкта һәм үзенчәлекле узды.

Әле кайчан гына гаилә учагында – йортларда, фатирларда гына билгеләп үтелгән Мәүлид мәҗлесләренең географиясе дә, аудиториясе дә, үткәрү мәйданнары да күзгә күренеп киңәйде хәзер. Мәдәният йортларына, ресторан-кафеларга, мәдәни-агарту үзәкләренә җыелып, шушы айның фазыйләте – Расулебезнең исламда тоткан урыны, дөнья халыкларының аны бәяләве, тормышы хакында кабат-кабат вәгазьләр тыңладык, касыйдәләр, мөнәҗәтләр ишеттек. Шатландырганы – әлеге мәҗлесләргә кайсы гына милләт вәкилләре кунак итеп чакырылмасын, чараларның туган телебездә алып барылуы булды.

БИТ 2

### Ак мәчеттә Мәүлид бәйрәме



БИТ 4

### Шиһабетдин Мәрҗанинең киң карашлылыгы



БИТ 5

### Чебеш тавыкны өйрәткән заманда...



БИТ 7

ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ КОРЪӘНИ КӘРИМДӘГЕ АЯТЬ-СҮРӘЛӘР УРЫН АЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛУЫГЫЗ СОРАЛА!

### МӨФТИ "МӨХӘММӘДИЯ" ШӘКЕРТЛӘРЕНӘ КОРЪӘННЕҢ ЯҢА БАСМАСЫН БҮЛӘК ИТТЕ

Бүген Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенең читтән торып уку бүлегендә белем алучы шәкертләр белән очрашты. Мөфти Камил хәзрәт һәр шәкерткә Коръәннең яңа басмасын бүләк итте һәм андагы үзенчәлекләрне аңлатты.

Мәгълүм булганча, узган ел Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Коръәннең яңа басмасын 10 мең тираж белән, ә соңрак 15 мең данә тираж белән дөнья күрде. Ике ел дәвамында әлеге эшне Коръәнне өйрәнү бүлеге, Коръәнхафизлар башкарып чыкты.

### ШЫГЫРДАНДА МӘҮЛИД БӘЙРӘМЕНЕҢ ЙОМГАКЛАУ КИЧӘСЕ

Декабрьнең 26сында Шыгырдан җәмигъ мәчетендә 2016 елның Мәүлид бәйрәменең йомгаклау кичәсе уздырылды. Бәйрәмгә чит төбәкләрдән килгән кунаклар, күрше авыллардан һәм үзебезнең авыл халкы, балалар чакырылды.

Мөхәммәт Пәйгамбәрнең (саләллаһу галәйһи вә ссәләм) һәм аның сәхәбәләре тормышына багышлап мөнәҗәтләр башкару, касыйдәләр уку, Аллаһ илчесен олылап салаватлар әйтү белән үрелеп барган бәйрәм тантанасы Шыгырдан җәмигъ мәчетендә өйлә намазыннан соң башланып китте. Кунакларны Мәүлид бәйрәме белән Мәскәү һәм Чуашстан мөфтие Әлбир хәзрәт Крганов, Чуашстан Диния Нәзарәте рәисе Мансур хәзрәт Хайбуллов тәбрик иттеләр. Җавап итеп кунаклар да үзләренең сәламнәрен тапшырдалар һәм үз төбәкләрендә уздыра торган Мәүлид бәйрәме үрнәге белән таныштырдылар.

Мәүлид аенда Чуашстан мәчетләрендә Пәйгамбәр турында вәгазьләр укылды, дини мәҗлесләр оештырылды. Мәүлид бәйрәмен мәчетләрдә генә түгел, ә һәр мөселман кешесе үзенең өендә якыннары, туганнары белән чәй табыны артына җыелып, Аллаһы Тәгаләне һәм аның илчесен олылап, догалар кылып, бигрәк тә сабый балаларны куандырып, аларга бүләкләр өләшеп үткәрде.

Килгән кунаклар һәм балалар рәсүлебезне олылап салаватлар әйттеләр, мөнәҗәтләр укыдылар. Күркәм кичә Пәйгамбәребезнең шәфәгатен өмет итеп, кылган гамәл-гыйбадәтләребезнең кабул булуын сорап, ил-көннәргә тынычлык, иминлек теләп дога кылу белән тәмамланды.

Кичен Шыгырдан мәдәният йортында балалар көче белән хәзерләнгән Мәүлид конөерты булды. Балаларны шатландырып Мәүлид бүләкләре тапшырылды. авыл халкы, ата-аналар балалар чыгышы белән канәгать булдылар.

### БАЛЫК БИСТӘСЕ РАЙОНЫНЫҢ ТӘБЕРДЕ ЧАЛЛЫСЫ АВЫЛЫ МӘЧЕТЕНДӘ БАЛАЛАР ӨЧЕН КЫШКЫ ЛАГЕРЬ ЭШЛӘДЕ

1-8 гыйнвар көннәрендә Балык Бистә районының Тәберде Чаллысы авылында балалар өчен кышкы һәм дини эчтәлекле лагерь эшләде. Мәктәп яшендәге балалар тәҗрибәле тәрбиячеләр ярдәме белән Коръән һәм намаз нигезләренә төшенде, Пәйгамбәребезгә багышланган вәгазьләр тыңлады. Дәресләрдән тыш, балалар иҗади бәйгеләрдә һәм спорт чараларында катнашты. Ябылу тантанасында һәр бала татлы бүләккә ия булды.

### ТАТАР АКСУЫ АВЫЛЫНДА ВӘГАЗЬ КИЧӘСЕ

11 гыйнвар көнне Татар Аксуы авылы мәдәният йортында вәгазь кичәсе булды. Авылның имамы Дамир хәзрәт Зарипов килгән кунакларга, авыл халкына рәхмәтен җиткерде. Фәнис хәзрәт Гайнатуллин мәчетләр каршында укыту белән бәйле мәсьәләләрне аңлатып үтте, авыл халкының дингә, гыйлемгә омтылырга тиешлеген искәртте. Буа шәһәренең "Хаҗилар" мәчетенең имамы Фәһим хәзрәт Сөләйманов авылдашларны ислам дине кыйммәтләрен аңлатты.

Очрашуга килгән авыл халкының сорауларына җавап бирелде.

# Мөфти Сүриягә эшлекле сәфәр кыла



Бу көннәрдә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Сүрия Гарәп Республикасының вакыфлар министрлыгы чакыруы буенча Димәшкъ (Дамаск) шәһәренә эшлекле сәфәр кыла.

Россия делегациясе составына шулай ук Русия мөселманнары диния мәҗлесе җитәкчесе, Мәскәү һәм Чуашстан мөфтие Әлбир Крганов, Кемерово өлкәсенең мөфтие Таһир хәзрәт Бикчәнтәев һәм РИУ проректоры Рөстәм Нургалиев керде. Әлеге сәфәр кысаларында кунаклар Дамаск ислам университеты һәм танылган «Әбу Нур» университетларында булды, биредәге җитәкчелек, мөгаллимнәр һәм шәкертләр белән аралашты.

Мөмкинлектән файдаланып дин әһелләре 2013 елда фаҗигале төстә вафат булган олуг галим Мөхәммәд Сәет Рамазан әл-Бутый каберен зиярәт иттеләр һәм рухына дога кылдылар.

Җирле мөселманнар Мөхәммәд Пәйгамбәребезгә ﷺ багышлап оештырган Мәүлид кичәсендә дә катнаштылар.

# Пәйгамбәребез юлы – безгә маяклы юл

*Дәвамы. Башы 1 нче биттә*

Казанның Яңа бистәдәге 1802 елны ук төзелгән Иске таш мәчеттә дә 14 декабрьда Мәүлид ашы күңелләрне сафландырган, Аллаһы Тәгаләнең сөекле хәбибе, ахырзаман Пәйгамбәре булган Расулебез Мөхәммәдгә (саләллаһу галәйһи вә ссәләм) карата олы хисләрне бергәләп салаватлар, мөнәҗәтләр әйтеп, үзләре язган шигырьләр укып узды. Пәйгамбәрләр тормышын, бигрәк тә Расулебез белән бәйле вакыйгаларны белү, хәтердә ныгыту ниятеннән кунаклар арасында викторина да уздырылды.

Биредә менә инде берничә ел хатын-кызлар өчен "Фәтима" мәдрәсәсе эшли икән. Казаныбыз мәчетләрендә остазлык итүчеләр өчен дини-милли традицияләребезгә нигезләп абыстайлык серләре төшендерелә, дини йолаларыбызны үтәү нечкәлекләре өйрәтелә икән.

Ерак дип тормыйлар, Казанның төрле почмакларыннан мөслимәләребез һәр чәршәмбедә бирегә сабак алырга ашыгалар. Үзенә күрә бер осталыкны арттыру, тәҗрибә уртаклашу курслары диярге дә була Иске таш мәчетнең болай эшләү, динебез чылбырындагы бу әһәмиятле вазыйфаларнең нечкәлекләрен өйрәтүгә алынуын.

Укыту, тәҗрибә уртаклашу буенча хәзерлекле команда да тупланган. Теләк булганда башкаларны кабатламаган эш юнәлеше табарга мөмкин икән дигән нәтиҗәгә килдек без 2010 елдан бирле биредә имамлык итүче Харис хәзрәт Нәҗмиев оештырган әлеге эшчәнлек белән танышкач. Һәм дин-ислам юлында хезмәт итәргә тырышучыларга дөрес итеп Коръән укырга өйрәтү, өйрәнгәнне шомарту, шушындый осталык дәресләре оештыру үзен аклый.

Мәүлид мәҗлесенә нур өстенә нур булып табиблар, ирле-хатынлы Рәшит Әгъзәмович һәм Фәния абыстай Җәләлиевалар килде. Алар туган авыллары Өркештә (Кукмара районы) быел гына ике катлы "Нур" мәчете ачкан, "Фәниябикә" мәдрәсәсе комплексы салып, 16 ел буена шунда тирә-яктагыларга дин-ислам нигезләрен, әдәп-әхлак тәрбиясен ирештергән игелекле затлар.

Халкыбыз яратып билгеләп үтә торган Мәүлид аена алар дин кардәшләребезгә үзенчәлекле бүләк хәзерләгәннәр: "Күңелләр дәвасы" дигән истәлекләр, нәфел намазлары, зикерләр, салаватлар тупланган китап чыгарганнар. Китапның мөхәррире, журналист Вәсилә ханым Рәхимова да, Фәния абыстай да мәҗлестәшләрнең өстәл китабы булырлык әлеге хезмәтләре белән таныштырдылар.

Иске таш мәчеттә хезмәт куючы остазлар тарафыннан ихластан әзерләнгән Мәүлид ашы күңелләрдә әнә шундый җылы хисләр калдырды. Ашыкмыйча, иркенләп кунак булдык, таныштык, үзара аралаштык. Инде күптәннән әни булган, дәү әниләр булган ак яулыклы мөслимәләребез биредәге "Дәү әниләр" мәктәбенә йөреп, дин-ислам юлында тагын нәрсәләр эшләп булачагын, үзебезгә алмашка килүче оньк-оныкчыкларыбызны әдәп-әхлаклы итеп, милли мирасыбызны, халкыбызның гореф-гадәтләрен саклаучы һәм дәвам итүчеләр итеп



тәрбияләүдә җиң сызганып өлеш кертергә тиешлегебезне ассызыкладык.

Мәчет эшчәнлегендә шушы юлны сайлаган Харис хәзрәт Нәҗмиев безне хөрмәтләп кунак итте, шушы юлда тырышырга өндәде.

Әле узган ел гына затлы итеп, җиренә җиткерелеп яңартылган, төзәтелгән борынгы тарихи мәчеттән беребез дә мәхәллә әзерләгән бүләксез һәм "Күңелләр дәвасы" дигән яңа чыккан китапсыз китмәде. Аллаһы Тәгалә тырышлыкларыннан разый булса иде дә, барчаларыбызга Пәйгамбәребезнең шәфәгате насыйп булса иде дигән теләктә таралыштык.

Әйе! Рабигуль әүвәл ае, Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафагә (саләллаһу галәйһи вәссәләм) карата булган хөрмәтебез күп мәчетләрдә, мәдрәсәләрдә барыбызны бер табынга җыйды.

"Гадел" мәчете елдагыча якшәмбе мәктәбендә сабак алучы сабыйлар өчен оештырды бу мәҗлесне: башыннан азагынача балалар алып барды мәҗлесне, азан әйтеп намаз да укыттылар, өйрәнгән сүрәләрен, салаватларын да кабатладылар, викторина уздырып, Фәния абыстай Җәләлиева оештырган бүләкләрне дә алдылар.

Исеме җисеменә туры килгән "Ярдәм" мәчете исә табын түренә инде ничә еллардан бирле биредә тырышып дин-ислам нигезләренә төшенүче күрмәүче, ишетмәүче, инвалид арбасында гына хәрәкәт итүчеләрне дәшкән иде.

Халыкка кабаттан кайтарып алынганнан бирле 25 ел дәвамында Кабан арты мәчете мәхәлләсе Мәүлид бәйрәмнәрен уздыруның юл башында тора. Быел мәхәллә тырышлыгы белән алты мәҗлес оештырылды.

"Регистан" ресторанына Казанның 11-нче мәктәп-интернатында тәрбияләнүче ятимнәр, "Азу" кафесына Дербышкидагы балалар йортында тәрбияләнүче гарип балалар чакырылса, Россия ислам университеты студентларын, мәчеттә якшәмбе мәктәбендә сабак алучы хатын-кызларны, төрле регионнардан Казанга килеп дөньяви белем алучы татар яшьләрен дә, шушы мәчетне үз итеп йөрүче дин кардәшләрне дә Мәүлид ае бер табын артына җыйды.

Дин әһелләре, Коръән хафизлар, галимнәр Мөхәммәд (саләллаһу галәйһи вәссәләм)нең олылыгын, күңеленең ихласлыгын, ислам юлындагы хезмәтләренең тулы бер өммәт өчен булуын төшендерделәр. Изге аебыз хөрмәтенә мәчетнең социаль ашханәсендә һәр атнада җомга намазыннан соң кайнар пылау көтте.

Аллаһы Тәгалә мөбәрәк кылган Рабигуль әүвәл ае әнә шулай күңелләрне сафландырды. "Өммәтем, өммәтем, өммәтем!" дип җан аткан Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (саләллаһу галәйһи вәссәләм) хөрмәтенә үткәрелгән мәҗлесләребез кабуллардан булса иде дә, һәм барыбызга да Расулебезнең шәфәгате насыйп булсачы дип догада торабыз.

**ВӘСИЛӘ РӘХИМОВА**

**КАЗАН ШӘҺӘРЕ**

# Татарстан мөфтияте 2017 елны "Галимҗан Баруди елы" дип игълан итте

Татарстан Диния нәзарәте тарафыннан 2017 ел "Галимҗан Баруди елы" дип игълан ителде. Ошбу тәкъдим белән бүген Диния нәзарәте бинасында үткән пленум җыелышында мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин чыкты һәм ул бертавыштан хупланды.

"Быел татар дин әһеле, мөфти Галимҗан Барудиның тууына февраль аенда 160 ел тула. Галимҗан Баруди кебек танылган дин әһелләрен белергә, аларның китапларын укырга бу юбилей үзе бер сәбәп. Шуның өчен дә бу елны "Галимҗан Баруди елы" дип үткәрергә тәкъдим итәм һәм рухи мирасыбызны өйрәнергә чакырам", - диде мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин.

Галимҗан Баруди күренекле дин галиме, мәшһүр җәмәгать эшлеклесе, педагог. 1882 елда Г. Баруди мәдрәсә ача, ул анда җәдитчә укыта, әтисенең хөрмәтенә мәдрәсәгә "Мөхәммәдия" исеме бирә. 1906 елда Казанда аның мөхәррирлегендә «Әд-дин вәләдәб» ("Дин вә әхлак") журналы чыга башлый.

Баруди Россия мөселманнарының сәяси тормышында да актив катнаша. "Иттифак әл-мөслимин" мөселман фиркасе Үзәк комитетының әгъзасы итеп сайлана. Россия мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте мөфтие вазыйфаларын да башкара.

# Татарстан мөфтие Казакъстан делегациясен кабул итте



Бүген нәзарәттә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Казахстан мөселманнары Диния нәзарәтенең хәләл һәм хаҗ департаменты җитәкчесе Бәйбит Мырзагильдиев һәм эшмәкәр Канат Рызкан углы белән очрашты. Әлеге очрашуда "Хәләл" стандарт комитеты рәисе Марат Низамов һәм аның урынбасары Хәйдәр Камалетдинов катнашты. Ике як Казакъстан кунаклары белән хәләл өлкәсендә үзара хезмәттәшлек итү хакында сөйләште.

# Мәүлид

Ислам дине тотучыларның дини бәйрәмнәре шактый. Аларның кайберләре бәйрәм, икенчеләре – кичә, өченчеләре – көн дип йөртелә.

Мөселманнарда иң олы бәйрәмнәр: Мәүлид, Ураза һәм Корбан бәйрәмнәре.

Мәүлид – Мөхәммәд пәйгамбәрнең (сәлаллаһу галәйһи вә сәлләм) туган көне һәм шул вакытта уткәрелә торган бәйрәм.

Мәүлид – гарәпчәдән "туу" дигәнне аңлата. Ул – мөселманнарның зур бәйрәмнәреннән берсе булган Мәүлид кичәсе. Икенче төрле аны Мәүлид ән-Нәби, ягъни "Пәйгамбәрнең тууы" дип тә йөртәләр. Әлеге көн, бөтен дөнья мөселманнарының дөнья вә ахирәт сәгадәтләренә сәбәп булган Мөхәммәд пәйгамбәрнең (аңа Аллаһының рәхмәте һәм сәламе булсын!) туган көне булу сәбәпле, мөбарәк көн исәпләнә. Бу көнне мәчетләрдә вәгазьләр сөйләнә.

Бер мөнәҗәттә мондый юллар бар:

И, кардәшләр, сөенеч безгә

Изге Мәүлид ае туды.

Шатлык булсын барчабызга

Изге Мәүлид ае туды.



Мәүлид аенда татар халкы яшәгән төбәкләрдә мәчетләрдә генә түгел, өйләрдә дә Мәүлид укыту, Мәүлид ашы уткәрү йолалары башкарылып килә. Иң әүвәл – салават, аннан соң зекер әйтәләр.

Татар халкының җирле үзенчәлекләрен, телне һәм йолаларны, гореф-гадәтләрне өйрәнү экспедицияләрендә йөргәндә безгә күп кенә авылларда бәйрәм уткәрүнең үзенә хас якларын язып алу да насыйп булды. Мәсәлән, Себердә – Тубыл-Иртыш якларындагы Абаул дигән авылда Мәүлид мәҗлесендә, кумәкләшеп, "Сөембикә" мөнәҗәтен әйтәләр:

Сөембикә, шатлан бүген,

Шатлана торган көнең.

Чөнки хәзрәте Мөхәммәд

Дөньяга туган бүген.

Әстерхан өлкәсенең Приволжский районы Килинчи (Киләче) авылында Мәүлид бәйрәмен бик зурлап, мәчеттә кумәк табын ясап уткәрүне күреп кайткан идек. Монда хатын-кызлар, өлкән апалар бәйрәмчә киенеп, һәркайсы шул якларга хас булган бәйрәм ашларын пешереп алып килә.

Без әлеге мәкаләбездә шушы авылдан алып кайткан язмаларыбызны, Нәсимә абыстай һәм өлкән хатын-кызлар сөйләгән мәгълүматларны китерәбез.

– Менә Мәүлид аенда матур итеп бәйрәмчәйгә җыелдык.

– Идәнгә тәстәрхан җәеп, туфәк-мендәрләргә тезелеп утырып, бәйрәмашлардан авыз иттек.

– Тәстәрханыбызда бәйрәмебезне сыйлап алып килгән, кардәшләребез үзләре пешергән ашлар тезеп салынган.

– Менә пәйгамбәребезнең яраткан ризыгы хәлвә (монда һәм алга таба нинди дә булса татлы ризык күз алдында тотыла; әйтик, милли ризыкларыбыздан чәк-чәкне дә шуңа кертеп карарга була. – ред.). Аны Мөслихә тәтәбез пешереп китерә ел да.

– Менә кыздырмыш (майда пешерелгән кумәч), үзем пешердем.

– Менә бавырсаклар, бәлешләр, кәнфитләр. Бавырсакларны тәстерханга чәчеп салабыз. Һәркем авыз итсен.

– Пәйгамбәребезнең (сәлаллаһу галәйһи вә сәлләм) туган көнендә Коръән укыткан кеше Мәүлид аена хәлвә катыра. Болай башка вакытларда инде кеше теләсә генә катыра хәлвәне, теләмәсә, юк. Мәүлид аенда хәлвә ясарга тырышалар, ул Пәйгамбәребезнең (сәлаллаһу галәйһи вә сәлләм) яраткан ризыгы булган. Шуның өчен хәлвә белән авыз итәләр.

Чын күңелдән тыңласаң, кил Мәүлидкә,

Укыйлар Мәүлидтә махсус каендә.

Сират кичмәгә эстәсәң, Мәүлидкә кил,

Җәннәт эстәр булсаң, ашыгып, Мәүлидкә кил.

Ошбу укыган Мәүлид догасының савабын барча өммәтләренә насыйп әйләсәң иде.

Ошбу укыган Мәүлид догалары Кыямәт көне кояшыннан күләгә булсын, Кыямәтнең авыр сәгатендә шәфәгать булсын.

Йә Раббым, шушы Мәүлид аенда Мөхәммәд Пәйгамбәребезнең (сәлаллаһу галәйһи вә сәлләм) туган көнен котлап, шушы дин мәҗлескә, бәйрәмчәйгә җыелган дин кардәшләребез укыган намазлар, хөтбәләрнең әҗер-савабын биргәй идең.

Йә Рабби, Мәүлид айларында шушылай итеп утырмага, намазларыбызны укымага насыйп ит!

**ФЛЁРА БАЯЗИТОВА**

**филология фәннәре докторы, Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре**

ГЫЙБАДӘТХАНӘ

# Рамазанга әзерләнер вакыт

*Дәвамы. Башы 1 нче биттә*


Чынлыкта, адәм баласына күтәрә алмаслык берни дә йөкләнелми. Аллаһы Тәгалә Коръән-Кәримдә моны Үзе вәгъдә итә:

«Бәгъзе кешеләр иман китереп изге гамәлләр кылдылар, һичкемгә көче җитмәгән йөкне йөкләмибез, мәгәр көче җиткәнне генә. Алар җәннәт ияләре, анда мәңге калачаклар» («Әл-Әгъраф» сүрәсе, 42нче аять).

«Аллаһы Тәгалә һичкемгә көче җитмәгән эш белән көчләмәс, мәгәр көче җиткән эш белән көчләр. Берәү Аллаһыга буйсынып изге гамәлләр кылса, файдалы эшләрне генә эшләсә – файдасы үзенәдер, әгәр берәү Аллаһыга карышып гөнаһларны, явыз эшләрне кәсеп итсә – газабы үзенә.

Аллаһыга итәгать итүче мөэминнәр әйтәләр: «И Раббыбыз, лязем булган изге гамәлләрне онытып калдырсак яки хаталанып гөнаһ эшләсәк, болар өчен безләрне газаб белән тотмагыз! И Раббыбыз! Әүвәлге өммәтләргә йөкләгән авып йөкләрне безгә йөкләмәгез! И Раббыбыз! Көчебез җитмәслек, сабыр итә алмаслык авыр бәлә-казаларны безләргә йөкләмә! Безләрне гафу ит һәм ярлыка һәм дә безгә рәхмәт кыл! И Раббыбыз, Син безнең хуҗа, барча хаҗәтләребезне Син генә үтисең, кәферләргә каршы торырга, аларны җиңәргә безгә ярдәм бир!» («Әл-Бәкара» сүрәсе, 286нчы аять).

Ураза михнәт түгел. Киресенчә, Раббыбызның бер рәхмәте, мәгъфирәте. Рамазан ае – нәфесебезне тәрбияләү өчен зур мөмкинлек. «Иркенлек»тә яшәргә күнеккән нәфесне Рамазанда да йөгәнли алмыйбыз икән – уйланырга кирәк. Рамазан – үз-үзебезгә хисап.




Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешү өчен ашау-эчү, якынлык кылудан гына түгел, яман сүздән, хәрам караштан, әшәке уйлардан арына алабызмы, әллә үзебезне Җәннәт иясе, дип хис итеп яшәвебезне дәвам иттерәбезме?

Уразага әзерләнү – Ахирәткә әзерләнү. Бүген нәфесебезне тәрбиялибез, кул, аяк, күз, тел, башыбызны гөнаһтан саклап яшибез икән – калебебез чистара, Раббыбызның рәхмәтен тагын да сөенеп кабул итә.

Таш булып каткан бәгырь рузасыз килеш тә Рамазан якынлашкан саен борчыла. Тизрәк үтсен иде, дип тели. Ягъни үз теләге белән мәгъфирәттән ваз кичә. Рамазанга әзер калеб исә ураза башланасы көнне зарыгып көтеп ала. Шәрәфле айның санаулы көннәре калганда борчыла. Киләсе елда бу бәрәкәткә ирешә алырмынмы, сәхәр, ифтар, тәравих, тәһәҗҗуд, игътикафлар кыла алырмынмы, дип уйлана. Һәм гает намазыннан чыккан мизгелләрдә үк киләсе Рамазанга әзерләнә башлый.

Әйе, кардәшләр, Рамазан аена әзерләнү Шәгъбан ае уртасында башланмый. Мөэмин-мөселман шушы елның фарыз уразасын тотып бетерүгә икенчесенә әзерләнергә тотына. Рамазан аенда гына суфыйланып, калган 11 айда гөнаһка батып яшәү мөмкин түгел.

Гел сүгенү сүзләре чыккан авыз белән зикер әйтү айһай авыр. Нәфескә бер җиңеллек бирдеңме – шунда ук эләктереп ала. Рамазанда җиңел, шайтаннар богаулы.

Ел буе шулай изгелектә булырбыз, дип уйлыйбыз да – Корбан гаетенә кадәр ничек тә түзәбез әле, ә анары инде авышабыз. Биш вакыт намаз тәрбия ул. Нәфесебезне йөгәнләү. Иртәнге намазга уянып, көндез эш вакытында гыйбадәт өчен вакыт табып әзерләнә мөселман Рамазанга. Аның һәр көне, һәр гамәле гыйбадәт.

«Уразага ничек әзерләнергә?» дигәндә, бердәнбер җавап: тәкъвалыкны арттырырга. Бүгеннән үк, шушы мизгелдән үк. Рәҗәб, Шәгъбан айларын көтмичә, Мөхәммәд (сәлаллаһу галәйһи вәсәлләмнең) сөннәтен торгызырга: тәһәҗҗудләр укырга, дүшәмбе, пәнҗешәмбеләрдә нәфел уразаларын тотарга һәм башка кешеләргә, башка җан ияләренә мөгамәләбезне камилләштерергә.

Аллаһы Тәгалә Рәхмәтле вә Рәхимле, ә без, Аның мәхлуклары, нинди? Явыз, үпкәләүчән, көнләшүчән. Берсе дә мөселман сыйфаты түгел. Барысы да күңелебезне карала торган халәтләр.

Калебебезне пакьләү өчен Рамазанны көтмик. Изге айга чиста күңел белән кереп, Рамазанның тәмен яхшырак тойыйк.

**ИНСАН ТАВИЛЕВ**

**МӘСКӘҮ ШӘҺӘРЕ**

ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ КОРЪӘНИ КӘРИМДӘГЕ АЯТЬ-СҮРӘЛӘР УРЫН АЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛУЫГЫЗ СОРАЛА!

# ИМАН ЮЛДАШ БУЛСЫН БЕЗЛӘРГӘ!

*Дәвамы. Башы 1 нче биттә*

### ШӘМАИЛ – ГАИЛӘ КҮРКЕ

Республикабыздагы дини вакыйгаларны барлаганда, Татарстан Диния нәзарәте һәм «Казан Кремле» дәүләт -архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы тарафыннан «Минем гаиләмнең шәмаиле» дигән Бөтенроссия конкурсы оештырылуын да әйтеп узарга кирәк. Әлеге үзенчәлекле проектта яшьләр дә, өлкән буын кешеләре дә актив катнашты. Оештыру комитетына 300ләп хезмәт кабул ителде. Россия төбәкләреннән генә түгел, Казакъстан һәм Австралиядән дә конкурсантлар бар иде.

Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батыр сүзләренчә, проектның төп максаты: татар милли сәнгате – пыялага ясалган шәмаилләрне популярлаштыру, яшьләргә иҗади үсештә ярдәм итү, яңа талантлар табу, тарихыбызга, бабаларыбызга карата хөрмәт хисе тәрбияләү, рухи культураны күтәрү, борынгы шәмаилләрне барлау һәм саклау.

### ТӨРЛЕ МИЛЛӘТ ВӘКИЛЛӘРЕ ДУСЛЫГЫ - КАЗАНЫШЫБЫЗ



Узган елның май аенда узган «Онлайн ММЧ: мәгълүмат кырында ДАИШка каршы тору» дигән халыкара фәнни-гамәли конференция игътибарга лаек. Биредә дөньяның танылган дин галимнәре, журналистлар, аналитиклар, дин белгечләре, журналистлар Россиядә тыелган ДАИШ террорчылык оешмасына мәгълүмати каршы тору ысуллары турында сөйләштеләр. Фикер алышуда дөньякүләм билгеле ислам галимнәре: Мисыр Президентының дини эшләр буенча киңәшчесе Госман Сәйд Әл-Әзһәри, Таба фондына нигез салучы һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең танылган вәгазьчесе Али әл-Җифри, Дамаск университеты докторы, Левант галимнәре җитәкчесе Мөхәммәд Тәуфыйк Рамазан әл-Бутый һ.б. журналистларга ДАИШ белән бәйле мәсьәләләрне аңлатты.

Шактый кызыклы, Татарстан өчен үзгә форматта оештырылган чарада конференциянең һәр катнашучысы үз фикерен белдерде. Мәгълүмат кырында ДАИШка каршы тору мәсьәләләре шактый четерекле һәм һәр каләм иясеннән әтрафлылык таләп итә. Мәгълүм ки, дөнья даими рәвештә төрле катлаулы мәсьәләләр, каршылыклар белән очрашып тора. Бездән еракта булган күңелсез вакыйгалар теләсә кайсы төбәктә кабатланырга мөмкин бит...

«Русия аль-Яум» телеканалының баш белгече Анна Беликова: «Татарстанда төрле милләт вәкилләре дус-тату гомер итә дигән сүзләрне еш ишетә идем. Күңелемдә ничек инде төрле милләтләр кечкенә генә республикада шулай яши ала икән дигән шик тә бар иде. Казанга килгәч сорауымны мөфтигә дә бирдем. Ә ул елмаеп, без бөтен милләтләрне дә якын күрәбез, яратабыз, диде. Чыннан да, сездә мөселман кызлары да шундый ачык күңелле, матур итеп киенеп, тышкы кыяфәтләре белән үк башкаларга үрнәк булып тора. Без бит мөселман ханымнарын үз-үзенә бикләнгән, артыгын сөйләми, ирләре артыннан гына йөри дип күз алдына китерәбез. Татарстанда, Казанда моның киресен күрдем. Төрле милләт вәкилләре белән уртак тел табып аралаша, фикер йөртә алалар. Минем фикеремчә, исламдагы четерекле мәсьәләләрне хатын-кызлардан башка хәл итеп тә булмый. Рухи яктан бай, мөлаем, теләсә кайсы аудиториядә төпле фикер әйтә алырдай хатын-кыз образын булдырырга кирәк. Сездә шушы сыйфатлар ачык күзгә ташлана... Шәрык белгече буларак шуны әйтә алам: Казан борынгы заманнардан бирле ислам фәлсәфәсе үзәге булган. Бу хакта без дөнья аренасында да аваз салырга тиеш. Татар исламы күпләрнең игътибар үзәгендә тора бит».

### АКАДЕМИЯ – ЗАМАН ТАЛӘБЕ



Узган елның 21 маенда, Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине рәсми рәвештә кабул ителгән көнне, Болгар ислам академиясе бинасы нигезенә капсула салу тантанасы узды. Биредә дөньяның төрле илләреннән килгән кунаклар катнашты. Болгарда төзелүче академия дөньякүләм көндәшлеккә сәләтле, башка илләрнең югары уку йортлары дәрәҗәсендә булыр дип көтелә. Әлеге югары дини уку йортында Татарстан яки Россиядән генә түгел, башка мәмләкәтләрдән килгән яшьләргә дә белем алу мөмкинлеге тудырылачак. Россиядә бүгенге көндә 7 ислам университеты бар. Болгар академиясендә әнә шул уку йортларын тәмамлаган белгечләр белемен арттырачак. Бүген Татарстанда шәригать докторлары юк. Болгар академиясе бу җитешсезлекне бетерергә дә ярдәм итәчәк.

Россия Ислам институты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин сүзләренчә, магистрлар һәм докторлар – санаулы гына товар булырга тиеш, шуңа күрә уку йортына артык күп студент җыю максаты куелмый. Магистратурага ел саен – 15, докторантурага 10 кеше генә алу күздә тотыла. Димәк, Болгар ислам академиясендә берьюлы 75ләп студент белем алачак. Моннан тыш, әлеге бинада төрле конференцияләр, курслар уздырылачак.

### ТАТАР ДИН ӘҺЕЛЛӘРЕ АКТИВЛАША

Узган елның җәй башында VII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы пленар утырышына Россиядән тыш, чит илләрдә дә имам булып торучы дин кардәшләребез килде. Форумда Россиянең 68 төбәгеннән 916 делегат катнашты. Казанда җиденче мәртәбә оештырылган милли, дини чарага беренче тапкыр гына аяк басучылар да бар иде. Алар: Еврей автономияле округы, Тамбов, Амур өлкәләре һәм Дагстан Республикасы вәкилләре.

Киров өлкәсе мөселманнары Дини нәзарәте рәисе, мөфти Зөфәр хәзрәт Галиуллин үз чыгышында тәрбия мәсьәләләренә кагылды. Мәчетләрдә очраган ямьсез күренешләрне туктатырга өндәде ул: «Татар халкын хәрәм җиңә башлады. Мәчетләрдә кулыңны тегеләй күтәр, болай ит дип сугышабыз... Мәчеткә урамда булганны алып керәбез. Ә бит мәчеттә булганны урамга чыгарырга кирәк. Хәрәм белән көрәшик! Без – муллалар – алдан барырга тиеш. Татар халкы үзенең мәгърифәте белән көчле. Революциягә кадәр мулла-имамнар мәчеткә килеп намаз укыган өчен акча алмаган бит. Әгәр дә имам мәчеттә балаларны укытмый икән, аңа нинди хезмәт хакы билгеләргә мөмкин?! Әгәр дә абыстай кызларны өйрәтми икән, аңа ничек ярдәм итәргә була?! Мәхәллә андыйларны ничек күтәрсен ди? Без татар телен дә саклаучылар бит. Күп җирдә мәктәпләр юк, ә менә ата-бабаларыбыз төзегән мәчетләр бар. Аларда без хезмәт куярга тиеш. Соңгы елларда ислам динен «культпросвет» эшчәнлегенә әверелдерә башладык. Имеш, конкурслар үткәрәбез... Кулыбызда шундый китап була торып, без нинди мәсьәләләрдә артта калырга тиешме?!»

### МИРАС БАРЛАНА

Татарстан Диния нәзарәтенең дәгъват бүлеге хезмәткәрләре совет чоры ишаннары турында фильм төшерде. Проект авторлары Дагстан, Үзбәкстанга барып шактый бай материал туплады. Татар дин галимнәренең дәһрилек елларындагы фидакарьләрчә хезмәтен бәян иткән фильм шактый кызыклы булып чыккан. Аллаһ юлында хезмәт иткән, җәмгыятебездә рухи-әхлакый кыйммәтләрне таратуга саллы өлеш керткән дини остазларга багышланган фильм үсеп килүче буынга гына түгел, тулаем җәмгыятьчелек өчен дә файдалы. Фильмны тәкъдим итү чарасына данлыклы ишаннарның дәвамчылары да килгән иде.

### КОРЪӘННЕҢ ЯҢА БАСМАСЫ



Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә нәзарәтнең махсус оештырылган Коръәнне өйрәнү бүлеге белгечләре тарафыннан әзерләнгән Коръәннең яңа нөсхәсе дөнья күрде. Китапта аятьләр 1803 елгы басмадагы кебек биттән-биткә күчкәндә өзелми, моннан тыш, ул хәрефләр саны буенча да Госманлы күчермәсенә туры килә. Укырга уңайлы булсын өчен хәрефләр ачыграк күренә. Татарстан мөфтие Коръәннең яңа редакциясе гарәп телен камил белмәгән кешеләргә изге китапны дөрес итеп укырга өйрәнү өчен бик уңайлы, ди.

### КОРЪӘННЕҢ АУДИОВЕРСИЯСЕ

«Хозур» нәшрият йорты һәм «Азан» мөселман радиосының уртак тышлыгы белән Коръәннең тулы аудиоверсиясе дөнья күрде. Аны Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин укый. Бу – изге китапны башыннан ахырына кадәр тыңлап була торган бердәнбер аудиоязма.

### КОРЪӘН – ТАТАР ТЕЛДӘ

2016 елда Коръәнне татар теленә тәрҗемә итә башладылар. Аны Россиядә гомер итүче барлык милләттәшләребез дә укый алачак. Проект авторлары бу эшне 2017 елда башкарып чыгачакбыз дип ышандыра. Татарстан Диния нәзарәте Изге китапны бүгенге татар теленә тәрҗемә итү буенча эшче төркемне раслады. Корьәнне татарчага күчерү омтылышлары моңарчы да булган. Изге китапны тулаем тәрҗемә итү өчен белемле белгечләр таләп ителә. Андый шәхесләребез дә бар икән. Шундыйлардан Тәлгать Таҗетдин, Әлбир Крганов, Рәфыйк Мөхәммәтшин һәм башкаларны атап үтәргә мөмкин.

ДӘВАМЫ 5 НЧЕ БИТТӘ

### АК МӘЧЕТТӘ МӘҮЛИД БӘЙРӘМЕ

Болгар шәһәрендәге Ак мәчеттә Мәүлид ән-Нәби бәйрәмен – Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (саләллаһу галәйһи вә сәләм) туган көнен билгеләп үттеләр. Кунакларны борынгы Идел буе Болгары башкаласы кояшлы матур көн белән каршылады.

Кунаклар бергәләшеп Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин артыннан икенде намазын кылдылар. Шуннан соң Ак мәчетнең конференцзалында Болгар ислам академиясен оештыручылары шурасының утырышы узды. Утырышта ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин, РФ мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать Таҗетдин, Россия мөфтиләр шурасы рәисенең урынбасары Рушан Аббясов, Татарстанның дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР президенты аппараты башлыгы Әсгать Сәфәров, Татарстан Республикасы президенты ярдәмчесе Камил Исхаков катнашты. Шулай ук Мәүлид ән-Нәби бәйрәменә Татарстанның төрле районнарыннан имамнар, Иваново өлкәсе мөселманнарының диния нәзарәте рәисе Фәрит Ляпин, Ульяновск өлкәсе мөселманнарының диния нәзарәте рәисе Илдар Сәфиуллин, Коми Республикасы мөфтие Вәлиәхмәд Гаязов, ХМАО мөфтие Таһир Саматов та килде.

"Ел саен без һәр мәхәлләдә Мәүлид бәйрәмнәрен үткәрәбез, ә быел – Дагстан мөселманнары диния нәзарәте белән берлектә үткәрдек. Алар мәчетләрдә генә түгел, зур шәһәрләрдә мәдәният йортларында да уза. Анда без пәйгамбәребез Мөхәммәднең, саләллаһу галәйһи вәссәләм, туган көне турында сөйлибез. Мөселманнар йортында вәгазь милли телләрдә барса, массакүләм бәйрәмнәрдә – рус телендә. Бу ай чараларга бик бай. Минем тизрәк кайтасым килә, чөнки Ханты-Мансийскийда, Пойковскида, Сургутта мине мәхәллә кешеләре көтә," – дип сөйләде Таһир хәзрәт.

Ахшам намазында имам Тәлгать хәзрәт Таҗетдин булды.

Бәйрәм гадәттәгечә Төркия Дин эшләре идарәсенең Коръәнне тикшерү һәм өйрәнү департаменты җитәкчесе Шахин Османның Корьән укуы белән башланып китте. Беренче чыгыш ясаучы Минтимер Шәймиев булды. Ул Мәүлид ән-Нәби бәйрәменең мөһимлеге, төзелүче Болгар ислам академиясе алдында торган бурычлар турында сөйләде һәм узган утырыш нәтиҗәләренең серен ачты. "Әйе, без академия бинасын төзербез, ә бит әле шәкертләрне табарга кирәк, кешеләргә булышырга, галимнәрне табарга". ТР президенты ярдәмчесе Камил Исхаков Болгар ислам академиясен оештыручылары шурасының рәисе итеп билгеләнде. Аның сүзләренә караганда, конкрет эшләр белән шөгыльләнә башларга кирәк: профессорлар, укытучылар составын формалаштырырга, академиянең потенциаль шәкертләре белән эш алып барырга.

Бөтенесе дә туган телләрендә чыгыш ясадылар, шул исәптән Аббясов та Равил хәзрәт Гайнетдиннең котлавын укыганда татар теленә күчте. Бары бер кеше – чит илдән килүче дини басмалар департаменты башлыгы Дияннат Салман Юксель генә төрек телендә сөйләде.

Камил хәзрәт Сәмигуллин Мәүлид бәйрәме турында сөйләде, ул Корьән аятьләре һәм хәдисләр ярдәмендә Рәсүлебез туган көнен билгеләп үтү, кайбер "галимнәр" әйткәнчә, зарарлы бидгат түгел, ә дин өчен файдалы эш булуын күрсәтте.

Тәлгать хәзрәт Таҗетдин: "Анда ни өчен укырга кирәк? Диплом өченме? Аны җәяүләр өчен җир асты кичүендә дә сатып алырга була. Юк, безгә белемле имамнар, галимнәр кирәк," - дип ассызыклады.

Мәчеттә татар һәм гарәп телләрендә иляхиләр һәм мөнәҗәтләр яңгырады. Мәүлид ән-Нәби касыйдәсе вакытында бөтен кешедән дә пәйгамбәребезгә салаватларны басып әйтүләрен сорадылар. Бәйрәм Татарстанның Баш казые Җәлил Фазлыев тарафыннан Корьәннән сүрә уку һәм Аллаһы Тәгаләгә дога кылу белән тәмамланды.

АЛЬФРЕД МӨХӘММӘТРӘХИМОВ

# ИМАН ЮЛДАШ БУЛСЫН БЕЗЛӘРГӘ!

*Дәвамы. Башы 4 нче биттә*

**ТАТАРСТАНГА ПАТРИАРХ КИЛДЕ...**

Узган ел республикабызга Мәскәү һәм бөтен Русь патриархы Кирилл килде. Ул тәре йөрешендә, Казан Изге Ана иконасы соборы нигезенә таш салу тантанасында катнашты. Казан Изге Ана монастыре территориясендәге чиркәү моннан 74 еллар элек, совет Хөкүмәте тарафыннан җимерелгән.

**ГАЕТ БӘЙРӘМЕН – ЯҢА МӘЧЕТТӘ**

Ураза гаетенең төп чарасы быел Казанның Галиев мәчетендә узды. Сүз уңаеннан, әлеге иман йорты



узган елның декабрь аенда төзекләндерелеп, яңадан мөселманнарга тапшырылган иде. Озак елларга сузылган тәнәфестән соң, биредә беренче тапкыр Ураза гаете намазы укылды. Шунысын да искәртик: Татарстан Диния нәзарәте дә мәчет комплексындагы бинага күчте.

**ТЕРРОРЧЫЛЫККА КАРШЫ ЯҢА САЙТ**

«Хозур» нәшрият йортында «Экстремизм. Яшьләр карашы» дигән түгәрәк өстәл оештырылды. Төрле яшьләр оешмалары вәкилләре җыелган конференциядә «Ислам террорга каршы» дигән яңа сайт та тәкъдим ителде. Татарстанда милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгыту, террорчылыкны һәм экстремизмны кисәтү, социаль, этник һәм конфессиаль нигездә килеп чыга торган низагларга чик кую, шулай ук террорчылык һәм экстремизм идеологиясенә каршы җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру максатында республикада «Экстремизмга – юк!» айлыгы игълан ителгән иде. Әлегә сайт рус телендә эшли. Әмма киләчәктә, проект авторлары ышандырганча, аның татар һәм инглиз телләрендәге версияләре дә булачак.

**ВӘГАЗЬЛӘР – ТУГАН ТЕЛЕДӘ**

12 августтан Татарстан мәчетләрендә җомга вәгазьләре фәкать татар телендә генә алып барылырга тиеш. Телнең зәгыйфьләнә баруы хәзер инде беркемне дә гаҗәпләндерми бугай. Дәүләт дәрәҗәсендә оештырылган проектлар, җәмәгатьчелек тарафыннан уздырылган акцияләр дә телебезне популярлаштыруга сүлпән генә тәэсир итә.

Ана телен саклауга динчеләребез дә үз өлешен кертә башлады диикме?!

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин карары белән республика күләмендә Коръән укучылар конкурсы узды. Проектта Татарстанның төрле районнарыннан Изге китапны матур итеп, мәкам белән укучылар катнашты.

Катнашучыларның әзерлек дәрәҗәсенә нәзарәтнең Коръәнне өйрәнү бүлеге җитәкчесе Илнур Хәйруллин, коръән-хафиз Хәсән Һәдия (Мисыр) һәм Күвәйт Мәгариф министрлыгы каршында эшләүче Коръән остазы Абдулҗәлил Касыйм бәя бирде. Хатын-кызлар арасында ярыш исә Казанның Зәңгәр мәчетендә барды. Ике номинациядә дә беренче урынны алучыларга хаҗга юлламалар тапшырылды. Икенче урынга лаек булучыларга – Гомрә хаҗына юллама, өченче урынны алучыларга ноутбуклар бүләк ителде.

**БАЛАЛАР АУДИТОРИЯСЕ ...**

2016 елда республика күләмендә үткәрелгән Коръән уку бәйгесе һәм балалар арасында «Гыйбадәте Исламия» китабына нигезләнеп оештырылган викторина күпләрнең игътибарын җәлеп итте.

***

Агымдагы елның февралендә татар дин галиме Галимҗан Барудиның тууына 160 ел тула. Галимҗан Баруди кебек танылган дин әһелләрен өйрәнү, аларның китаплары белән танышу өчен бу юбилей – үзе бер сәбәп. Яшьләргә стимул булсын өчен дин әһелләре конкурслар да оештырырга ниятли.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

# Шиһабетдин Мәрҗанинең киң карашлылыгы

**Шиһабетдин Мәрҗанинең олпат шәхесе XIX гасырдагы ислам дөньясында тау түбәседәй калкып тора. Бу вакытта мөселманнарның җанлы фикере белән ургып торган чишмәләре кибеп корый кебек, элек чәчәк аткан һәм көчле ислам цивилизациясе үле Сахара чүлләренә охшап кала. Шушы рухый чүл өстендә схоластлар (схоластик рәвештә фикер йөртүчеләр) тырышлыгы белән барлыкка китерелгән “Заманы иҗтиһад монкарыйз (Иҗат заманы бетте)” тәгъбиренә (сүз әйләнмәсенә) кергән ахырзаманның әңгер-меңгерле рәшәсе тибрәнеп торган кебек була.**

Менә Аллаһы Тәгалә адәми затны, акыл кебек могҗиза иңдереп, азат итеп яраткан дип әйтергә батыр бер кеше килеп чыга. Шуңа күрә хөр иҗат – азат акылның табигый халәте ул. Кеше яши, фикерле икән, ул иҗади эзләнә ала һәм моны эшләргә тиеш тә. Мөселман дөньясы өчен бу яңа идеяләрне халыкка иң әүвәл Шиһабетдин Мәрҗани аңлатып биргән, һәм шуның белән ул иҗтиһад (мөстәкыйль фикер йөртү. – ред.) ишеген яңадан ачкан сыман була. Мөселман яңарышы белән яңалык процесслары озак вакыт буена әфганлы Җамалетдин әл-Әфгани, мисырлы Мөхәммәт Абдо һәм төрек Әхмәт Мидхәт паша исемнәренә бәйләп йөртелә. Фәкать XX йөзнең икенче яртысында гына шәркыят (көнчыгыш турындагы фән) һәм дин белгече, американлы Александр Беннигсенның исламны яңартуда татар фикер ияләренең өстенлеге турындагы тезис (раслама) куелган һәм төрле яктан фәнни нигезләнгән хезмәтләре пәйда була. Мөселман реформизмы эшлеклеләре плеядасында (күренеклеләр төркемендә) ул Габденнасыйр Курсави (1776-1812) белән Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889) исемнәрен исбатлады.

Американлы ислам белгече Россиянең ябык булуы сәбәпле, бу илгә буйсындырылган халыкларның ислам дөньясындагы уртак процесслардан аерылган булуын һәм шул сәбәпле алардагы галимнәрнең дөнья күләмендәге танылу алуга ирешмәгәнлекләрен билгеләп үтә. А.Беннигсен фикеренчә, тарихи гаделлекне кире кайтарырга вакыт җитте. Америкалы мәшһүр галим, шәрык һәм ислам белгече фикеренә без дә кушылабыз һәм бу мәкаләбездә Шиһабетдин Мәрҗанинең бөек реформатор, милли яңарышка (күтәрелешкә) нигез салучы икәнлеген исбатларбыз.

Шиһабетдин Мәрҗани – барыннан да бигрәк бөек реформатор. Татарның, бөтен ислам дөньясының фикере авыр таш белән бастырылып, кешенең мөстәкыйль фикер эшчәнлегенә “Заман иҗтиһад монкарыйз” дигән богаулар салынган бер заманда ул шәхескә фикер иреге, иҗат хокукы таләп итеп чыга, рухый хәяттә (тормышта) иске, таушалган авторитетларның монополиясен җимерә, мөселман дөньясы өчен иҗтиһад капусын (капкасын) ача. Ул татарны торгынлык йокысыннан уятучы, уйлау-фикерләү офыгын арттан алга таба, үткәннән киләчәккә таба борып куючы була. Аның бөек реформаторлыгының асылы әнә шуннан гыйбарәт. Бу – татарның, бөтен мөселман дөньясының рухый хәятендә инкыйлаб була.



Мәрҗанине Италия ренессансының атасы А.Данте белән чагыштырырга мөмкин. Аның исеме Европаның мәшһүр дини реформаторлары Мартин Лютер (1483-1546), Ян Гус (1371-1415) һәм башкалар белән янәшә торырлык.

Мәрҗанинең бөек каһарманлыгын үз чорында аңлап та, бәяләп тә бетермәгәннәр. Чөнки ул үзе яшәгән мохиттән, җәмгыятьтән күпкә алда барган, югары күтәрелгән шәхес була. XIX гасыр уртасында мөселман дөньясында калкып чыккан биек тау башына менү дә, аны аңлау-бәяләү дә җиңел булмагандыр, күрәсең. Әмма бу затның татар рухый алгарышындагы (тәрәккыятендәге) бөек ролен аннан соң килгән буыннар бик яхшы аңлаган һәм югары бәяләгән. Татар әдәбияты классигы, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Г.Ибраһимов, мәсәлән, 1915 елда аның 100 еллык юбилей уңае белән “Мәрҗани – безнең таңыбызның Чулпаныдыр”, – дип яза.

Шиһабетдин Мәрҗанинең реформаторлык эшчәнлеген шартлы рәвештә ике этапка бүлеп карап булыр иде: дини реформаторлык этабы (XIX гасырның 70 нче елларына кадәр) һәм мәгърифәтчелек этабы (XIX йөзнең 70-80 нче елларында). Мәрҗани бу өлкәдә эш алып барган ватандашы һәм рухый остазы Габденнасыйр Курсави фикерләре белән якыннан танышу теләгеннән, аның “Мәҗмуга” хезмәтен кулына ала һәм бу әсәр Мәрҗанинең реформаторлык (реформалар ясау эше) һәм фәлсәфи карашлары формалашуга нык тәэсир итә.

Әлбәттә, Шиһабетдин Мәрҗани Бохара һәм Сәмәрканд якларында укып, зур яңа белемнәр туплап, яңа фикерләр үзләштереп, унбер елдан соң туган ягына кайта. Бу вакытта Мәрҗани, иске карашлы руханыйлардан аермалы буларак, мәдрәсәләрдә укыту системасына яңалыклар кертергә тулысынча әзер булып кайта.

1850 елның 30 мартында аны Казанның Җәмигъ мәчетенә имам-мөдәррис итеп билгеләү турындагы указга кул куела. Ул җиң сызганып эшкә тотына. Татар сәүдәгәре Ибраһим Гобәйдулла улы Юнысов (1806-1886) белән Шиһабетдин Мәрҗани арасындагы киеренке мөнәсәбәт турында да әйтеп узарга кирәк. Мәчет һәм аның каршындагы мәдрәсәнең матди хәле күп яктан Казан шәһәр Думасы гласные (1871-1886) И.Юнысовка бәйле булуын да истән чыгарырга ярамый. Аз гына каршы әйтүне дә кабул итәргә күнекмәгән И.Юнысовка Мәрҗанинең бәйсез, горур табигате баштан ук ошамый. Ул ике мәртәбә аның указын да алып карый, ләкин үзенә буйсындыра алмагач, җимерелә башлаган мәдрәсәне сипләү өчен акча бирми. Үз чиратында, Мәрҗани дә Юнысовка бил бөгәргә теләми, яңа бина төзелешенә мәчеткә йөрүчеләрдән акча җыя (хәзерге “Мәрҗани” мәчете). Ул үзе төзеткән шул мәчеттә гомеренең соңгы көннәренә кадәр белем бирә.

Мәрҗанинең даны читләргә дә тарала. 1870 елда ватанында һәм мөселман Көнчыгышында аңа шөһрәт китергән, дини реформаторлык идеяләре белән сугарылган “Назурател-хак” (“Хакыйкатьне күзаллау”) хезмәте дөнья күрә. Шиһабетдин Мәрҗани, үзенең рухый остазлары Г.Утыз Имәни, Г.Курсави традицияләрен яңа рухый шартларда дәвам иттереп һәм тирәнәйтеп, дини реформаторлыкның күренекле идеологына әйләнә. Ул түбәндәге хәдисне китерергә ярата: “Пәйгамбәр сүзләреннән күренгәнчә, “Аллаһы Тәгалә һәр гасыр башында мөселман җәмәгатенә дингә яңарыш кертүчене җибәрә”. Исламда XII гасырдан соң “иҗтиһад ишекләре” ябылмаган дигән нәтиҗәгә килә ул. Мәсәлән, әңгер-меңгер төшкәнче төнге намазның зарурлыгын күзәтеп, Казан төбәгендә ястү намазының җитүен катгый таләп итүнең дөрес түгеллеген аңлатудан бигрәк, үзенең дини өйрәтмәләрне ничек күзаллавы турында яза.

Шиһабетдин Мәрҗанинең иҗатында мәгърифәтчелек һәм дини реформаторлык идеяләренең тыгыз бәйләнештә үсешен Г.Ибраһимов та күрсәтеп үтә. Ул моңа үзенең “Бөек остазымызның кайбер тәэмифләре” исемле мәкаләсендә Шиһабетдин Мәрҗанинең “Назурател-хак” дигән әсәренә биргән анализында бәян итә. “Бөек галимне бу китабын язарга этәргән нәрсә, – дип күрсәтә Г. Ибраһимов, – заманында зур бәхәсләр тудырган ястү намазы мәсьәләсе шәфәкъ бетеп җитмәс борын таң ата башлаган җирләрдә ястү фарызмы, түгелме? Мәгърифәтче галим шәригатьне хәреф буенча гына аңлап җәйнең озын көннәрендә ястү намазын фарыз түгел дип санаучыларның фикерләренең дөрес түгеллеген ышанычлы дәлилләр белән ачып сала.

“Мәрҗани дөньяның билгеле бер заманда яратылу турындагы фикерләрне дә кире кага. Аның өчен һәрдаим хәрәкәттә булган реаль әйберләрдән аерылган заман юк. Вакытлы яшәүче әйберләрдән башка күзалламаган заман – буш хыял. Заман барлыкка килүдән элек заман булу мөмкин булмаган нәрсәдер” (Мәрҗани. – Казан, 1915. – 239 б.).

Бу китап нәшер ителгәч, дин галимнәре һәм зыялылар арасында каршылыклы кискен бәхәсләр чыккан һәм фанатик муллалар тарафыннан Мәрҗанигә һөҗүм итүләр башланган.

Шиһабетдин Мәрҗани “Назурател-хак” хезмәтендә Курсави тарафыннан алга сөрелгән идеяләргә ачыклык кертә, тирәнәйтә, үзенең дини мәсьәләләргә карата булган уй-фикерләрен нигезләп күрсәтә. Китабының теге яки бу бүлеген язганда, галим Коръәннән өзекләргә, пәйгамбәр сүзләренә таяна. Аның уенча, укучы, әлеге мәгълүмат белән танышкач, нәтиҗәне үзе ясарга тиеш.

Мәрҗани билгеләвенчә, кешедә теге яки бу мәсьәләгә карата үз карашы һәрчак булмаска да мөмкин, бу очракта ул тәкълидкә мөрәҗәгать итәргә тиеш була. Мәрҗани тәкълидне иҗтиһадка каршы куя, фәлсәфә фәнен югары бәяли.

Мәрҗани мөселман хокукын XIX гасырның икенче яртысы татар җәмгыяте ихтыяҗларына һәм таләпләренә яраклаштыра.

**ЛИНАР ЗАКИРОВ**

**ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ**

ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ КОРЪӘНИ КӘРИМДӘГЕ АЯТЬ-СҮРӘЛӘР УРЫН АЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛУЫГЫЗ СОРАЛА!

# ГАЛИМҖАН БАРУДИНЫҢ ТУУЫНА 160 ЕЛ

**2017 елда татар халкының мәшһүр дин эшлеклесе Галимҗан Барудиның тууына 160 ел тула. Шул уңайдан, Татарстан мөселманнары диния нәзарәте пленумы 2017 елны Галимҗан Баруди елы дип игълан итәргә карар кылды.**

Гомумән, Татарстанда дини мирасыбызны барлау, атеистлык чорында оныттырылган шәхесләрнең исемнәрен, аларның хезмәтләрен халыкка кайтару кебек мактаулы эшләр соңгы елларда активлашты. 2015 ел шулай Республика мөфтияте башлангычында «Татар дин әһелләре елы» шигаре астында узды. Быел исә аерым бер шәхескә күбрәк игътибар бирү ниятләнелде. Раббыбыз шулай итеп һәр мөхтәрәм шәхесебезне олылау мөмкинлеген бирсен.

Элек еллар бер кешегә багышланылмый иде, нигә беренче булып Баруди сайланылган, кебек сорау, мөгаен, урынсыздыр. Түгәрәк дата – бер сәбәп кенә. Нишләтәсең, чорыбыз шундый: кармакка җим салу гына җитми. Ә максат изге – мөмкин кадәр күбрәк кешегә Галимҗан Баруди турында мәгълүмат җиткерү. Аның дин өлкәсендә куйган хезмәтләрен күрсәтеп, милләтебез белән горурлану өчен тагын бер сәбәп булдыру. Гаҗәп бит: кешеләр университетлар тәмамлый, икенче югары белем ала, дөнья гизеп чыга, ә Галимҗан Баруди белән Галимҗан Галиевның бер үк кеше икәнен белми. Гәрчә Казанда бу шәхес белән турыдан-туры бәйле урыннар сакланып калып, кайсылары яңадан торгызылып, бүген дә мөселман өммәтенә хезмәт итсә дә.

Галиев мәчете

2015 елда Казанда төзекләндерүдән соң Галиев мәчете ачылды. 1798–1801 елларда Муса Мәмәшев акчасына салынган Бишенче җәмигъ мәчет, «Муса бай мәчете» 1882 һәм 1897 елларда көньяк һәм төньякка таба зурайтыла. Бу эш сәүдәгәрләр Ибраһим Уразаев, Мөхәммәтҗан Галиев һәм Исмәгыйль Имәнколов хисабыннан башкарыла. Дин-ислам өчен акчаларын кызганмаган бу өч татар бае арасындагы Галиев фамилиясен йөртүчесе – Галимҗан Барудиның атасы Мөхәммәтҗан була. Галимҗан Галиев, тумышы белән Казан уездының Кече Кәвәл авылыннан (хәзер Биектау районына керә) булса да, балачагы башкала белән бәйле. Төгәлрәк әйткәндә, хәзер Казанның Киров районына кергән Дары заводы бистәсе белән. Мөхәммәтҗан байның зур йорты шунда урнашкан була.

Баруди тәхәллүсе дә очраклы түгел. Баруди – дары – порох. Бүген Галиев мәчете Мөхәммәтҗан әфәнденең дә истәлеген саклый. 1857 елның февралендә дөньяга килгән Галимҗанны 1862 елда «Касыймия» мәдрәсәсенә бирәләр.



Анда ул гыйлем алуның бөтен баскычларын уза, әле үзе дә шәкерт килеш остазлыкка керешә. Бохарада белем эстәгәннән соң Галимҗан Баруди Казанга әйләнеп кайта һәм 1882 елдан бүгенге Галиев мәчетендә хезмәт куя. Гыйбадәт йорты имам-хатыйбы, консерватив карашлы Мөхәммәтйосыф Сәгыйтов белән Галимҗан Барудиның фикер каршылыгы – ике шәхеснең генә түгел, кадимилек һәм җәдитчелекнең үзара бәрелешүе була. Әмма монысы инде аерым бер зур мәсьәлә.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе

1883 елда Диния нәзарәте Галимҗан Барудига мәдрәсә ачарга рөхсәт бирә. Әтисе ярдәме белән Галимҗан хәзрәт данлыклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен оештыра. Яңа уку йортына беренче нигез ташын Нәкышбәндия суфичылык тәрикатенең мәшһүр шәехе Зәйнулла ишан Рәсүлев сала. Галимҗан Баруди Зәйнулла ишанның мөриде, ягъни укучысы була. Остазының рөхсәте белән үзе дә мөридләр ала, белемнәрен яңа буын мөселманнарга җиткерә һәм Зәйнулла ишанның «белем бирү системасын камилләштерүдә иҗтиһад кылыгыз, шул юлда хезмәт куегыз, милли һәм дини мәсьәләләрдә фетнә чыгармагыз һәм бүленмәгез» дигән васыятенә гомере буе тугры кала. Дистә еллар узганнан соң өммәтнең яңа вәкилләре – XXI гасыр мөселманнары бердәм булуларын, тарихи чылбырларны тагын да ныгытырга теләүләрен исбатлады. 2016 елда Татарстан мөфтиятенең зур делегациясе Дагыстанга сәфәр кылды.

Диндәш республиканың башкаласы Махачкала шәһәрендә Зәйнулла ишан Рәсүлев исемендәге мәчет ачылды. Бу вакыйгага килеп җитәр өчен Дагыстанга, Татарстанга да бик зур сынаулар, бихисап сандагы югалтулар аша узарга туры килә...

Галимҗан Баруди Россиядә мөселман белем бирү системасын реформалауга бик зур өлеш кертә. Уку-укыту процессында үзгәрешләр турыдан-туры аның исеме белән бәйле. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шул яңарышның башында тора. Бүген дә илдә дини белем бирү системасын төзү процессы бара. Татарстан бу мәсьәләдә, әлбәттә, алдынгылар рәтендә. Атеистлык чорында өммәттән тартып алынган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бүген янәдән яңаруның авангардында. 2016 елдан «Мөхәммәдия» Казан мөселман югары мәдрәсәсен Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзе җитәкли. Мөселман белем бирү системасында барган үзгәрешләргә тирән кереп китмичә, бер генә яңалыкны күз уңыннан чыгармыйк: «Мөхәммәдия»дә укыту хәзер бары тик татар телендә алып барыла.

Уку әсбапларыннан канәгать булмаган Галимҗан Баруди аерым хезмәтләрне үзе яза. Алар арасында тел, дин мәсьәләләренә кагылганнары гына түгел, хәтта арифметика буенча китап та була. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе тиз арада дан казана. Остазлар арасында Әбүбәкер Терегулов, Сәет-Гәрәй Алкин, Йосыф Акчура кебек үз заманының алдынгы карашлы, тирән белемле шәхесләре була. Халкыбызның Фатыйх Әмирхан, Мәҗит Гафури, Фәтхи Бурнаш, Кәрим Тинчурин, Нәкый Исәнбәт, Хөсәен Ямашев, Камил Ягъкуб, Бакый Урманче кебек уллары биредә белем ала. XX гасыр башында мәдрәсәдә 500ләп шәкерт укуы мәгълүм. Галиев мәчете һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөселманнарны берләштерүче бер үзәккә әйләнә.

Тарих кабатлана. Шул ук сүзләр бүгенге чынбарлыгыбызга да туры килә. 2016 елда ТР мөселманнары диния нәзарәте Галиев мәчете йорты янындагы бинага күчә. Хәзер инде бу комплекс мөселманнарны берләштерүче бер үзәккә әйләнеп килә. Биредә дини чаралар, дәресләр уза, шул исәптән татар телен камилләштерү дә мөмкин. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе дә күршедә генә.

Сайланылган беренче мөфти

Болганчык еллар башланганчы, Галимҗан Баруди «Әд-дин вә әл-әдәб» журналын чыгара. Бүгенге дини матбугат – шул чорда чыккан «Шура», «Дин вә мәгыйшәт», «Әд-дин вә әл-әдәб»ләрнең дәвамы. 1907 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе каршында якын-тирә дини мәктәпләрдә укытучы остазлар өчен белем эстәү курсларын оештыра. Игътибар итик: бүген дә имамнар, мәдрәсә укытучылары, мәчетләр каршындагы дини курслар остазлары өчен квалификация күтәрү курслары даими үткәрелеп тора. Яңа буын да Зәйнулла ишан васыятен үтәүдә иҗтиһад кыла.

Галимҗан Барудины исә дүрт еллык сөргенлек көтә. Җәза вакытының бер өлешен аңа Ливан белән Сүриядә үткәрү насыйп була. Кире Казанга әйләнеп кайтканнан соң ул актив иҗтимагый тормышын дәвам иттерә. «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясе әгъзасы буларак өммәт өчен тырыша. Бүгенге мөселманнар өчен дә әһәмияткә ия вакыйга 1917 елда, Февраль инкыйлабыннан соң була. Тарихтан билгеле булганча, Мәскәүдә мөселманнарның Бөтенроссия җыены уза һәм Галимҗан Баруди Россия мөселманнарының үзәк диния нәзарәте мөфтие итеп сайланыла. Ягъни ил тарихында беренче тапкыр мөфти югарыдан билгеләнелми, ә сайлап алына. Бүген дә мөселман җитәкчеләрен өммәт үзе сайлый.

Шул катлаулы елларда да Галимҗан Баруди дини агарту турында борчыла. Шул мәсьәлә буенча фикер алышу максатыннан 1918 елда Уфада имамнарның Бөтенроссия киңәшмәсе дә уздырыла. Әмма ил башка юл белән китә. Дәүләтнең яңа җитәкчелеге, шул исәптән Сталин белән очрашудан Баруди канәгатьлек алмый.

Баруди урамы

1920 елда Галимҗан Баруди үзенең 4228 томлык китапханәсен Татарстанга тапшыра. Бүген бу хезмәтләр Казан университетының Фәнни китапханәсендә саклана. Киң колачын җәеп килгән ачлык елларында кешеләр бер тәгам ризык өчен җанын да сатарга әзер чакта Баруди рухи азык турында уйлый. Инде китапларны урнаштыргач та үзен түгел, диндәшләрен кайгырта: Үзәк диния нәзарәте ачлыктан интегүче Идел буе һәм Урал халкына ярдәм сорап мөселман илләренә мөрәҗәгать итә. Мөфти Сталинга хат яза, үзе белән очрашу җаен эзли. Әмма 1921 елда Мәскәүдә вафат була. Шулай да Казанда, Татар бистәсе зиратында җирләнелә. Гаҗәп бит: кешеләр университетлар тәмамлый, икенче югары белем ала, дөнья гизеп чыга, ә Галимҗан Баруди кабереңең Габдулла Тукай кабере янында икәнен белми. Баруди урамы да Казанда 2005 елда гына барлыкка килә. Бүген тарихыбызны барлау эше, Аллага шөкер, киңрәк колач алды.

Ислам динен саклау, үстерү өчен җаннарын фида кылырга әзер шәхесләребезнең исемнәрен белү стадиясенә җиттек. Хәзер инде хезмәтләрен өйрәнүгә дә керешсәк була. Гасырлар чылбыры кабаттан тоташты. Өзелмәслек итеп ныгытасы иде...

**ИНСАН ТАВИЛЕВ**

**МӘСКӘҮ ШӘҺӘРЕ**

НӘСЫЙХӘТ

# Җәннәткә купшылык кертми

**Җеназаларда катнашканда вафат булучының туганнары тарафыннан динебезгә хас булмаган ялгыш гамәлләрне күрергә туры килә. Мәчетләрдә һәм мөселман кирәк-яраклары кибетендә мәетне җирләү өчен бөтен әйберне юнәтергә була. Ә менә ритуаль хезмәтләр салонында һич кирәкмәгән әйберләрне дә тәкъдим итәргә мөмкиннәр, анда бит динне белгән кешеләр утырмый. Кайгылы вакытта кеше акчасын кызганып тормый, барысын да сатып алырга әзер, тик якыны җәннәткә генә керсен (ул шулай уйлый). Ритуаль хезмәтләр салоннарында бөтен әйберләр дә күркәм, мәет өстенә яба торган җәймәсенә кадәр. Җәймәгә алтын хәрефләр белән Коръән сүрәләре язылган, кара тасмалар белән веноклар тора. Барысы да бик матур һәм бик кыйммәт. Тик болар берсе дә җәннәткә кертә торган түгел, бу — акчаны исраф итү генә. Җәннәткә кешене холкы-гамәле, изге эшләре, кылган гыйбадәтләре кертә. Мәетне юып-пакьләгәч, ак кәфенлеккә төрү дөрес.**



Кайберәүләр мәетнең баш очына мендәр, астына одеял, күкрәгенә Коръән сүрәсе куеп калдырырга тырыша. Болар барысы да ялгыш гамәлләр. Адәм баласы туфрактан яралган – туфракка тапшырылырга тиеш.

Кайчагында низаглар да чыккалый. Юыпкәфенләп җирләргә әзер мәетнең тәһарәте бозылырга мөмкин: аның өстенә күз яше тамарга, пычрак төшәргә тиеш түгел. Юганчы күрмәгән булса, еракта бик якын кешесе кайтып төшсә генә битен ачып күрсәтергә ярый.

Җеназага тиешенчә киенеп килмәгән: башы, балтыры ялангач, изүеннән күкрәге күренеп торган кыска җиңле күлмәктән килгән хатын-кызга кисәтү ясасаң – хәзрәт-абыстайның капризы дип кабул итәләр. Ә бит бу — шәригатебезнең катгый таләбе.

Зират — купшылык һәм экскурсия урыны түгел, ә үзебезгә дә үлем киләчәген уйлап, вафат булган якыннарыбызны дога белән искә алу урыны. Соңгы йортыбызга 2 метрлы мәрмәр һәйкәлләр дә, купшы чардуганнар да кирәкми. Исеме, атасының исеме, туганы һәм үлгән еллары язылган кечкенә таш җитә. Фотосурәт куелмый, веноклар кую да динебездә исрафчылык дип исәпләнә.

**РӘМЗИЯ ШӘЙМӨХӘММӘТОВА**

**ӘГЕРҖЕ ШӘҺӘРЕ**

# Мәүлид ән-Нәби

Дәвамы. Башы 1 нче биттә

**- Мөхәммәд Пәйгамбәрнең ﷺ туган көненә карата нинди мөнәсәбәт Ислам өчен традицион булып санала?**

- "Мәүлид" сүзе – туу, дөньяга килүне аңлата, ә "мәүлид ән-Нәби" – "Мөхәммәд Пәйгамбәрнең тууын". Рабигыль-әүвәл аеның 12 кичәсендә булган бу вакыйга бар мөселман өммәте өчен дә бөек вакыйга булып исәпләнә. Аллаһ Рәсүленең ﷺ шул ук айда вафат булуы да билгеле.

Радикаль карашлы кайбер кешеләр мәүлидне билгеләп үтүне кабул итмиләр, аны бидгать (яңалык кертү), хәрам гамәл дип атыйлар. Ләкин, бу вакыйганы билгеләп үтүнең мөмкинлегенә һәм тиешлеге турында күп дәлилләр бар. Бохариның сахих (дөрес) хәдисе буенча, Пәйгамбәрнең ﷺ абыйсы Әбү Ләһәб кебек кафер кеше дә хәтта, Мөхәммәднең ﷺ тууына шатланып, үзенә файда алган. Аның колы Сувайба аңа шатлыклы бу хәбәрне җиткергәч, ул бу вакыйга хөрмәтенә аны коллыктан азат иткән һәм мәҗлес оештырган. Гомере буе Мөхәммәднең ﷺ Исламга өндәвенә каршы көрәшкән, Исламга каршы торган Әбү Ләһәбнең вафатыннан соң бер ел вакыт үткәч, Габбас (галәйһи сәлләм) аны төшендә күргән. Ул төш күргән вакытта Әбү Ләһәб аңа әйткән: "Үлгәннән соң мин тынычлыкка ирешеммәдем, әмма җәһәннәмдә һәр дүшәмбе көн саен минем газапларым җиңеләйтелә". Аллаһы Тәгалә, Мөхәммәд Пәйгамбәрнең ﷺ дүшәмбе көнне дөньяга килүе сәбәпле, хәтта аңа да газапларын җиңеләйткән. Ә Мөхәммәд Пәйгамбәрне ﷺ сөйгән һәм аңа салават – сәламләүләр әйткән гади мөселманнарны Аның нинди рәхмәтләре көтүе турында ул вакытта ни әйтергә була?! Пәйгамбәрнең ﷺ: аңа без ни кадәр күбрәк һәм ихласрак салават әйтәбез, - безнең өчен шул кадәр үк яхшырак, - дип әйткән хәдисләре бар.

Рабигыль-әүвәл аенда без Аллаһның Рәсүлен ﷺ сөю хисләре белән искә алабыз һәм Аллаһтан моның өчен күп саваблар да алабыз. Аллаһы Тәгалә шулай дип әйтә: "Аллаһ үзе вә фәрештәләре пәйгамбәр г-мгә салават әйтәләр, ий мөэминнәр, сез дә пәйгамбәргә салават әйтегез һәм сәлам әйтегез" (Коръән, "Әхзаб (Гаскәрләр)" сүрәсе, 33:56). Без бу көнне Аллаһның рәхмәте белән Мөхәммәд Пәйгамбәр ﷺ кебек бөек кешенең дөньяга килүенә һәм безнең тормышыбызны нурга күмүенә шатланабыз. Әгәр дә бу вакыйга булмаса, җирдәге кешеләр Исламны белү мөмкинлегеннән, Раббыбызга – Бердәнбер Аллаһыбызга сөю хисе, Аңа гыйбадәт кылган вакытта җан тынычлыгы, рух камиллеге алу бәхетеннән мәхрүм булырлар иде. Шуның өчен, Пәйгамбәрнең ﷺ дөньяга килүе уңаеннан шатлык белдерү, аны билгеләп үтү, аңа салават әйтү - Аның безгә Үз Рәсүлен ﷺ җибәргәне өчен, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт белдерүне аңлата.



**- Мәүлидне билгеләп үтү – татарларның күп гасырлык традициясе. Элек бу ничек үткәрелгән булган? Ә хәзер мәүлид ән-Нәбине ничек билгеләп үтәләр?**

- Татарлар элекке вакытлардан ук Исламда тәсәввефләр, тарикатьләр юлына тәкълид иткәннәр. Суфыйчылык мөселманнары – үзләренең Аллаһка иман китерүләре турында фикер йөртүче, үзләре, үз күңелләренең пакьлыгы, ихсан – Аллаһка ихлас гыйбадәт кылу өстендә эшләүче кешеләр. Мөхәммәд Пәйгамбәргә ﷺ салават әйтеп, алар аның аша Аллаһы Тәгаләдән бәрәкәт алалар.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә Пәйгамбәргә хөрмәт белән мөрәҗәгать итәргә кирәк икәнлеге турында әйтә: "Ий мөэминнәр, тавышларыгызны пәйгамбәр тавышыннан артык күтәрмәгез, вә бер-берегезгә дәшкән кеби пәйгамбәргә дәшмәгез (ягъни хөрмәт белән дәшегез), гамәлләрегезнең юкка чыгу ихтималы булганы өчен, әмма үзегез юкка чыкканны сизмәссез" (Коръән, 49:2). Аллаһы Тәгалә, башка пәйгамбәрләргә мөрәҗәгать иткән вакытта, аларга исемнәре белән генә мөрәҗәгать итә мәсәлән: "Йә Ираһим, яки йә Нух, әмма Мөхәммәд Пәйгамбәргә ﷺ мөрәҗәгать иткән вакытта, аңа ихтирам күрсәтеп: "Ий, Пәйгамбәр!", "Ий, Рәсүл!", "Ий, киемгә бөркәнгән!" - дип мөрәҗәгать итә. Моннан Аллаһе Тәгаләнең Үзенең үк Үзенең бу сөеклесенә олуг хөрмәт күрсәтүе һәм аңа зур әһәмият бирүе турында сөйли. Ә ни өчен безгә, Аллаһның гади бәндәләренә, аны тиешенчә хөрмәт итмәскә? Пәйгамбәрнең ﷺ исемен ишетү белән, без: "Аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!", - дияргә тиешбез. Хәдистә шулай дип әйтелә: "Аллаһ рәсүленең ﷺ исемен ишетү белән, аңа салават әйтмәгән кешегә үкенеч булсын". Күргебезчә, Коръән һәм хәдисләр буенча, Мөхәммәд Пәйгамбәргә ﷺ сәлам җиткерү – мәҗбүри гамәл. Аллаһы Тәгалә Изге Коръәндә, аның рәсүл, чын пәйгамбәр, соңгы пәйгамбәр икәнен раслап, бары тик дүрт урында гына "Мөхәммәд" исемен куллана, әмма дәшү монда юк: "Мөхәммәд ничкем түгел, мәгәр Аллаһның хак рәсүледер ..." (Коръән, "Гимран" сүрәсе, 3:144). "… ул Аллаһның рәсүле вә пәйгамбәрләрнең ахыргысыдыр" (Коръән, "Әхзаб (Гаскәрләр)" сүрәсе, 33:40). "Мөхәммәд г-м Аллаһның рәсүледер ..." (Коръән, "Фәтех (Җиңү)" сүрәсе, 48:29). "... вә Мөхәммәд г-мгә Аллаһ иңдергән Коръәнгә ышандылар ..." (Коръән, "Кыйтал (Мөхәммәд)" сүрәсе, 47:2).

Безнең әби-бабайлар бу аят һәм хәдисләр белән, әлбәттә, таныш булганнар. Нәкъ менә шул сәбәпле бездә мәүлид ән-Нәбине билгеләп үтү традициясе хәзерге вакытка кадәр сакланып калган. Үзенең шәхси сыйфатлары белән бар мөселманнар өчен дә үрнәк булган иң камил кеше – Пәйгамбәрне ﷺ сөю һәм аңа якынлашу аша гына – яхшырак һәм Сөннәткә, Аллаһның үзенә якынрак булуга ирешергә була. Бөек галим бине Сирин үзенең әтисе белән хаҗ кылырга юлга чыккач, юлда аның әтисе вафат була һәм йөзе аның карая. Кайгыдан сагышка баткан бине Сирин әтисенең тәне янында йоклап киткәч, ул төшендә Мөхәммәд Пәйгамбәрне ﷺ күрә. Пәйгамбәр аңа шулай ди: "Уян! Синең әтиеңнең йөзе нурланды . Миңа салават әйткән өчен, Аллаһы Тәгалә аның бар яшерен гөнаһларын да ярлыкады". Шуннан соң, табигатьтән кучкыр булган аның йөзе яктырып китә. Аның юлдашларының моңа игътибар итүләре буенча, шуның сәбәпле, хаҗ кылган вакытта бине Сирин Пәйгамбәргә ﷺ әчтән генә гел салават әйткән.

**- Тәвәссел – Аллаһы Тәгаләгә Мөхәммәд Пәйгамбәр ﷺ аша мөрәҗәгать итү рөхсәт ителәме?**

- Дога укып, Мөхәммәд Пәйгамбәр ﷺ аша Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итү - ихлас иманлы мөселманга теләкләренең Аллаһка ирешүенә ярдәм итә: "Ий Аллаһ! Безнең бөек Мөхәммәд Пәйгамбәребез ﷺ хөрмәтенә, миңа шуларны-шуларны бир!". Пәйгамбәргә ﷺ карата зур сөю хисен белдерү – ширек булып санала алмый, ул – Аллаһка якын килү ысулы. Гомәр бине әл-Хәттаб (галәйһи сәлләм) хәлифә Аллаһның Рәсүле каберe янында үксеп елаган Билалны (галәйһи сәлләм) туктатмаган. Хәдисләр буенча, Аллаһы Тәгалә сайлап алган иң камил кешеләр – пәйгамбәрләр үз каберләрендә намаз укыйлар. Мәүлид һәм Аллаһ рәсүленә ﷺ сәлам җиткерү – безгә зур бәрәкәт һәм Аллаһның рәхмәтен алырга ярдәм итә.

**ФӘРИТ БАТЫРШИН**

**КАЗАН ШӘҺӘРЕ**

САБЫЙЛАР

# Чебеш тавыкны өйрәткән заманда...

Уку елы башында Казанның Гаилә мәчетендә мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен "Тәрбияле бала" дигән балалар үзәге ачылды. Мәчет каршында болай да 32 төркемдә өлкәннәргә һәм мәктәп балаларына дини гыйлем бирелә, төрле дини чаралар, бәйрәмнәр үткәрелеп тора; бәләкәчләр белән эшләү бик җаваплы да, мәшәкатьле дә, авырга туры килмәс микән, дип баштарак шикләнеп караучылар да булган иде.

- Беркемгә ияру дә, "мода"дан калышмаска тырышу да түгел бу, ә тормыш таләбе, - дип, Татарстан мөфтие урынбасары, Гаилә мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин әлеге проектка алынуның сәбәпләрен аңлатты. – "Алтыннан да кыйммәтле, оҗмах нигъмәтләреннән дә кадерле булган нәрсә – тәрбияле баладыр. Ата һәм ана өчен тәрбияле бала кебек олы байлык һич булмас. Тәрбияле бала дөньяда җанга шатлык һәм ахирәттә йөзгә аклык китерер" – бу сүзләр күренекле татар дин әһеле Ризаэддин Фәхретдиннеккә. Хәзерге көндә бала тәрбиясенә тиешле игътибар биреләме - дүрт бала атасы буларак, иң әүвәл мин шул хакта уйландым. Ачылганнан бирле безнең мәчеттә мөселман балалар лагерьлары оештырылып килә. Мәктәп яшендәге балаларын шунда китергән ата-аналар еш кына: "Хәзрәт, кече баламны да алып калыгыз әле, бераз дини тәрбия керер ичмасам", - диләр. Өйдә генә өйрәтеп ятарлар иде дә, күбесенең дини гыйлеме чамалы. Әле, киресенчә, безгә йөргән балалар әтиәниләренә үзләре дин сабагы бирә, намаз укырга өйрәтә. Чебеш тавыкны өйрәткән бик тә үзенчәлекле заманда яшибез бит ...



Шулай итеп, тиешле документлар әзерләнеп, бина бөтен шартына туры китереп җиһазландырылганнан соң, югары махсус белемле ике педагог, бер коръәнхафиз, пешекче һәм җыештыручыдан торган коллектив Рөстәм хәзрәтнең ныклы контроле астында, Аллаһыга тапшырып, эшкә керешә. Башта 4-5 бала кыяр-кыймас кына мәчет бусагасын атлап керсә, бер ай эчендә аларның саны 14-кә җитә. Минем баламны да алыгыз инде, дип әле дә ялварып килә торалар, тик әлегә үзәкнең мөмкинлекләре чикле...

... Иртәнге 9-нчы яртыларга балалар җыелып бетте. 5-6 яшьлек шушы сабыйларның дин сабагы өйрәнүләрен үз күзләрем белән күрәсем килеп, укытучылары Әлфия Яфаровага иярдем. Әмма дәрес мин күз алдына китергәнчә башланмады – балалар алты яшьлек "имам"га оеп, башта 2 рәкәгать мәчет намазы укыдылар. Бөтен шартын китереп, хәрәкәтләрен җиренә җиткерергә тырышып укуларына сокланып туя алмадым, бер ай эчендә моңа ничек ирешеп була икән ул?! Намаздан соң түгәрәкләнеп утырып зикер әйтә башладылар, балалар унлап зикерне яттан беләләр. Аллаһның 58 исемен һич ялгышмыйча, тәртибе белән санадылар, бу дәрестә 59 нчысын өйрәнергә тиешләр икән. Аннары өлкәнрәкләр кулларына "Мөгаллим сәни"не алды, ә бәләкәйләр яңа сүрәне ятларга керешге. "Монда әти-әниләрнең ярдәменнән башка гына булмый, - ди Әлфия ханым. – Өйдә кайсы хәрефләрне язарга, нинди сүрәне кабатларга - көндәлекләренә язып җибәрәбез. Балалар бик тиз отала, нәтиҗәсен күреп, үзебез дә сөенәбез".

Коръәннән тыш балалар бирердә пәйгамбәрләр тарихы, гарәп, рус, татар, инглиз телләрен, әдәп-әхлакка, тәһарәт алырга, намаз укырга өйрәнә. Мавыктыргыч уен, әкиятләр, сәхнә күренешләре рәвешендә алып барылган 20 минутлык бу дәресләр сабыйларны һич ялыктырмый.

- Беренче максатыбыз – балаларга динебезне тормыштан аермыйча өйрәтү. Безнең үзебезне, тегендә дин бар, монда дин юк, дип үстерделәр. Дин ул, кайберәүләр уйлаганча, мәчеткә керү белән башланмый, ә тугач та башланып, ләхеткәчә дәвам итә. Элек мәдрәсәләрдә дөньяви фәннәр белән бергә дин дә укытылган. Нинди гыйлемле, бөтен ислам дөньясына танылган татар галимнәре чыккан ул мәдрәсәләрдән! Шунысы куанычлы – хәзер дини гыйлемне балачактан бирүнең әһәмиятен аңлаучылар артканнанарта бара, ата-аналар күбрәк дин дәресләрен укытуыбызны сорыйлар. Безнең хәзерге тагын бер өстенлегe шунда – дөньяви фәннәр дә кергәч, бирердә балалар мәктәпкә тулы әзерлек алып чыга, ата-аналарга аларны шәһәр буенча тагын каядыр йөртәсе юк. Ә әзерлек дәрәҗәсе дөньяви балалар бакчаларындагыдан һич калышмый. Төркемдәге балалар саны аз булганлыктан, һәркайсына педагогның игътибары җитә, - ди балалар үзәге җитәкчесе Алсу ханым Хәйруллина.

**НӘҮБӘҺАР КӘБИРОВА**

**КАЗАН ШӘҺӘРЕ**

## АКТУАЛЬ СОРАУЛАРГА ХӘНӘФИ МӘЗҺӘБЕ БУЕНЧА ҖАВАПЛАР

### – Намаз кылмаган кешенең Коръән укуы дөресме?

– Коръәнне укыр өчен, әлбәттә, кеше пакь булырга тиеш. Тәһарәтсез һәм госелсез аны кулга алу һич тә дөрес түгел. Күңелдән тәһарәтсез укырга ярый, ә госелсез күңелдән укый алмый.

Намаз укымаган кешенең Коръән укырга теләге бар икән, тәһарәтле булса, укырга мөмкин.

### – Аш мәҗлесендә Коръән нинди тәртиптә укыла?

– Аш мәҗлесләрендә кеше кайсы сүрәләрне белсә, шуны укырга ярый. «Фатиха»ны да һәм башка сүрәне дә укырга мөмкин.

### – Хатын-кызларга аш мәҗлесләрендә кычкырып хатем укырга ярыймы?

– Әгәр дә бу мәҗлестә ирләр булмаса, ул вакытта хатын-кызларның кычкырып Коръән укуы дөрес була.

### – «Тәбарәк» сүрәсен мәҗлестә тулысынча укыргамы, бүләргә дә ярыймы һәм аны багышлар өчен нинди догалар укырга кирәк?

– «Тәбарәк» («Мүлек») сүрәсен дә, башка озынрак сүрәләрне дә мәҗлесләрдә тулысынча да, бүлгәләп тә укырга ярый. Нинди сүрә-аять укысаң да, кальб-күңелеңдә булган саф уйларыңны, фикерләреңне, теләкләреңне догага әйләндерсәң, хәерле булыр. Нинди дога укып багышларга дигәндә, берәүнең язган догасын алып, Аллаһы Тәгаләгә багышлаганга караганда, күңелеңдә булганы белән багышлау, теләкләреңне теләү күркәмрәк булуы шиксездер.

### – Коръән аятен укыгач, 3 мәртәбә «Куль-һүәл-лаһу»не, «Сүбехәнраббика»ны укып тәмам итү дөрес, диеп язылган. Табында да, мәет озаткачта шушы аятьтән соңгы догаларны күмәкләп уку дөресме? Әллә укучы мөселман үзе генә тәмам итәргә тиешме?

– Әлбәттә, Коръән укуны нинди сүрә вә аять белән тәмамласаң да дөрес булыр, вә сез әйткән тәмамлау ысулы да тыелмаган. Укырга өйрәнү вә өйрәтү ниятеннән генә Коръәнне күмәкләп уку рөхсәт ителә.

### – Коръән аятен укып, дога кылганда табында иң өлкән кеше башлап кул күтәрү мәҗбүриме, әллә аять укучы мөселманмы?

– Дога кылганда иң әүвәл дога укучы кулын күтәрә. Ә дога укучы мәҗлестә утыручылар арасыннан билгеләнелә. Әмма дога кылучының, Коръән укучының мәҗлестәге иң өлкән кеше булуы һич тә шарт түгел.

### – Коръәнне урыс алфавиты белән өйрәнеп укырга ярыймы, тәҗвидсез ярыймы?

– Тәҗвид белән уку вәҗиб, диелгән хәдис бар. Әгәр Коръәнне тәҗвид белән өйрәнеп укысаң, нинди хәреф белән булса да ярый. Дөрес укымасаң, гарәп хәрефе белән булса да хата – хата инде ул. Әгәр шуның мәгънәсе дә бозылырлык игътибарсыз укысаң, яки дәрәҗә өчен, яки мал җыяр өчен укысаң, гөнаһлы булганы һәркемгә билгеле инде. Син укыма алай, ярамый, дип туктатмыйча, менә болайрак, дип төзәтсәң, һәр ике як саваплы була. Үзеңә хаҗәтләреңне теләп уку дөрес.



### – Гыйбадәтханәдә телевизор карау дөресме?

– Мәчеттә гыйбадәт кылынырга тиешле. Әгәр дә мәчетнең аерым ишекле бер бүлмәсендә Ислам диненә өнди, тәһарәт алырга, намаз укырга өйрәтә торган видеофильмнар карала икән, ул рөхсәт ителә. Телевизордан без кайбер файдалы нәрсәләрне алабыз. Чит илләр мәчетләрендә телевизорлар юк. Ләкин Ислам мәркәзләрендә бар. Аның өчен аерым бер урын булса – әйбәтрәк. Мәчеттә телевизор карап утыралар икән, дигән сүзләр чыгып, бөтен дөньяга таралып, гайбәтегезне сөйләгәнче, сөйләмәүләре яхшырак.

### – Мәчет булмаса, аерым бүлмәдә намаз уку дөресме?

– Әлбәттә, биш вакыт намазны кайда укысаң да фарыз үтәлә, өстеңнән төшә, әмма мәчет – Аллаһы Тәгалә өе. Аллаһ йортында укуның 27 өлешкә дәрәҗәсе артык. Өендә камил тәһарәт алып Аллаһы йортына барып, намаз укыр өчен өеннән чыкса, беренче адымы гөнаһларын пакьлый, калган адымнары кыяміттә дәрәҗәсен күтәрә, диелгән бит. Шулай булгач, хәлегездән килгәнчә, мәчеткә барырга тырышыгыз. Мәчетләр югында халык: «мәчет булса икән», диде, ә инде мәчетләр булды да, анда бармас өчен сәбәп эзли башладымы? Мәчет никадәр ерак булса, әҗере дә шулкадәр күп аның. Хәдистә әйтелә: «Әгәр берәү дөньядан иманлы булып китүен теләсә, һәм кальбнең йомшак булуын һәм теләгенә ирешүне теләсә, ятимне хөрмәтләсен, мәчеткә барганда адымны күп кылсын, бер намазын укыгач, икенчесен көтеп алсын», дигән.

### – Коръән тәфсирен дога итеп укырга ярамый, дип ишеттек. Ягъни мәеткә яки үзең өчен тәфсирне укырга ярамый, дип.

– Коръән тәфсирен укып үзеңнең иманыңны ныгытасың һәм үзеңә тиешле бурычларыңны һәм нәрсәләрдән тыелырга кирәген беләсең. Шулай итеп, әҗер-саваплар эшлисең. Догаларны Коръән-Кәримнән уку хәерле.

### – Коръән ашларында багышлау һәм дога укуны кул күтәргән килеш башкару озакка сузыла. Куллары калтырау аркасында ашка үрелергә дә читенсенеп утыручы өлкәннәр өчен бу газапка әйләнә башлый. Дога кылу вакытында багышлауда кул күтәрмичә, дога укыган чакта гына кул күтәрергә ярыймы, әллә баштан ук күтәрергәме?

– Пәйгамбәребез (сәлаллаһу галәйһи вә сәлләм) үзенең бер хәдисендә кыскарак кылынган догаларның хәерлерәк булуы хакында әйтте. Шуның өчен, минемчә, күтәрелгән куллар арыганчы кылынган догалар шәригатькә генә түгел, акылга да сыймый. Бәгъзе бер кешеләр мөһим булмаган нәрсә турында сөйләп, күп догалар кылып, намазларын калдыралар, мәчеткә бармыйча калалар. Шуның өчен һәрбер кеше доганы күркәм итеп, озакка сузмыйча кылырга тиеш.

### – Аш мәҗлесендә мөнәҗәт әйтергә ярыймы?

– Хатын-кызлар аерым үткәргән мәҗлестә эчтәлеге шәригатькә каршы булмаган, музыка кораллары кулланмыйча, мәҗлестә катнашучыларда динебезгә мәхәббәт тәрбияләү максатыннан мөмкин.

### – Гарәп хәрефләрен укый алмасаң, ничек Коръән тутырырга? Коръәнне ничек, күпме укырга?

– Белмисең икән, хәлеңнән килмәгән эшкә керешергә кирәкми. Коръән тутырмасаң, син мөселман түгел, дигән сүз юк бит. Хәлеңнән килсә, күпме укый аласың – шулкадәр укы, нинди хәреф белән язылган булса да, чын кальбтән, җиренә җиткереп, дөрес итеп укырга кирәк. Укы да, Аллаһым, кимчелек-хаталарны гафу ит, дип дога кыл. Коръәннән үзегезнең күңелегезгә кайсы өлеше якын, шунысын укыгыз, дигән Аллаһы Тәгалә. Шуңа күрә, хәлеңнән килгәнен укы да дога кыл.

**Габделхак хәзрәт Саматовның «Шәригать: вәгазь, хөкем, фәтва, җавап-савап, киңәшләр» китабыннан**

**Газетаны гамәлгә куючы**
«Путь» хәйрия фонды.
Газета Татарстан мөфтияте рөхсәте белән бастырыла

**Редакция шурасы**
Рәисе – Дагстан республикасы мөфтие, Әхмәд хаҗи АБДУЛЛАЕВ

Татарстан республикасы мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН

Мәскәү Ислам институты ректоры Дамир ХӘЙРЕТДИНОВ

**Баш мөхәррир**
Азиз МИЧИГИШЕВ

**Мөхәррир**
Ләйлә ХӨСӘЕНОВА

**Баш мөхәррир урынбасары**
Фәрит Батыршин

**Гамәлгә куючы мөхәррир**
Мөхәммәт РӘХИМОВ

**Әдәби мөхәррир**
Рәйсә СӘГАДИЕВА

**Менеджмент**
Абдулсабир АХМЕДОВ

**Веб-версия**
Мөхәммәтрасул ЗАҺИРОВ

**Компьютер төркеме**
Ренат ИСЛАМОВ
Гайсә ОМАРОВ

**Индекс 35888.**
**Подписка в любом почтовом отделении России.**
При перепечатке ссылка обязательна.
Набрано и свёрстано на компьютерной базе газеты «Ас-Салам».
Отпечатано в филиале ГУП МО «КТ» «Мытищинская типография» по адресу: 141009, Московская область, г. Мытищи, ул. Колонцова, 17/2.
Заказ №**120.** Тираж **999** экз.
Подписано в печать (факт) 15.01.2017 в 15:00
(график) 15.01.2017 в 15:00
**Адрес редакции и издателя:**
367015, РД, г. Махачкала, ул. Ярагского, 128.
**E-mail:** assalamweb@gmail.com. **www.**assalam.ru
**Телефоны**
Редакция: +7-904-662-18-75 , +7-928-530-59-70
Подписка и доставка по РТ: +7-987-172-2000
Отдел распространения по РФ: +7-926-222-78-75

ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ КОРЪӘНИ КӘРИМДӘГЕ АЯТЬ-СҮРӘЛӘР УРЫН АЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛУЫГЫЗ СОРАЛА!